Георгий Ибушев
Рәхмәт сиңа, җыр!
ШИГЫРЬЛӘР

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007
УДК 821.512.145-1:784
ББК 84 (2Рос=Тат)-5:85.319
И12

**Ибушев Г.М.**

Рәхмәт сиңа җыр: шигырьләр, җырлар / Георгий Ибушев; кереш сүз авт. Равил Фәйзуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 207 б. –2000 данә. – ISBN 978-5-298-01479-3

Татарстанның халык артисты, җырчы Георгий Ибушев күңеле нечкәргән минутларда кулына каләм алып, хис-кичерешләрен шигъри юлларга салып, кәгазьгә төшерә. Китапта аның әнә шул шигырьләре, җырлары тупланган.

ISBN 978-5-298-01479-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Ибушев Г.М., 2007

**ШАГЫЙРЬ ҖЫРЧЫ**

Моннан җиде-сигез ел элек Георгий Ибушевның «И җыр гынам, җырым...» дигән хезмәтен бик тәэсирләнеп укырга туры килгән иде. Нинди хезмәт ул? диярсез. Аның жанрын төгәл генә әйтә дә алмыйм. Фәлсәфи трактат та ул, публицистик уйлану да, нәсер, ягъни чәчмә формада язылган шигырь дә... Татар җырының язмышы, киләчәге турында уй-фикер йөртә җырчы Георгий, сызлана, бәргәләнә... Әйе, татар җыр-моңы турында күпләр уйлана булыр, әмма профессиональ җырчы кеше сүзенең үтемлелеге бүтән инде ул... Уртак эшебез, рухи сәнгатебез өчен борчылганы, янган-көйгәне, йокымсыраган күңелләрне уятканы өчен рәхмәт аңа!

Гомумән, Георгий Ибушев иҗатына сокланулы мөнәсәбәттә мин. Моннан 20 еллар элек аның башкаруында «Безнең ил» җырын («Безнең ил – уйнар-көләр җир, безнең ил – сандугач сайрар җир!..») йотылып тыңлаганнан башланды бугай бу тартылу. Аннан соң күпме җырларын тыңларга туры килде, күңелдә һәрчак, һәркайда рәхмәтле хис-тойгы калды. Хәер, бу тойгының дөреслеген документ-язма белән дә раслап була икән әле.

2000 елны «Казан утлары» журналында Г. Ибушев турында кыска гына бер язмам басылып чыккан иде. Шуның бер өлешен китереп узыйм.

«Талантлы җырчы Георгий Ибушев турында берничә кәлимә сүз-фикер әйтү теләге күптәннән күңелдә йөри иде. Өстәвенә ул миңа якташ та әле, туган авылларыбыз арасы нибары егерме чакрымлап кына (элеккеге Кызыл Йолдыз районына керә иде безнең авыллар). Нининдидер якынлык, уртаклык бар: сөйләштә дә, гадилектә дә, фикерләүдә дә. Сирәк кенә булса да, концерт-чыгышларда күрешкәләгән дә булгалады. Шул кыска гына аралашу мизгелләрендә дә якты хис-хатирә калган. Ясалмалык юк бу кешедә. Садәлек, эчке чисталык, яхшы мәгънәсендәге авылча беркатлылык... Күрү-аралаша алу үзе Ходайның бер бүләге булса, җаныңа иш кеше белән сөйләшү үзе бер бәхет. Керәшен егете Георгий белән күрешкәч, йөзгә елмаю куна, күңелгә нур иңгәндәй була. Күрәсең, бәхетледер ул, фәкать бәхетле кеше генә шундый аура тудыра ала. Һәрхәлдә, «язмышым – җыр» дигәнне ул яшьли үк аңлаган, максатына әкренләп кенә ирешеп барган шәхес. Тормышта бу кадәресе дә инде аз түгел.

Георгий Ибушев – чишмә тавышлы җырчы. Белгечләр андый тавышны югары регистрдагы җиңел альтинотенор диләр. Табигатьнең сирәк бүләге. Шулай булгач, аның кадерен белеп яшәү һәм иҗат итү сорала. Ә моның өчен акыл, белем һәм инану да кирәк. Георгийда боларның һәммәсе дә бар, минемчә. Җырчының йөзен аның репертуары билгели. Халык җырлары җәүһәрләре, классик композиторларның әсәрләре – менә аның иҗат мәйданы. Ышанычлы, ныклы юл. Бәхете (күбрәк без – тыңлаучылар бәхете) – җырда сезонлы кумир булу юлын сайламавы. Чорның һәм Җырның символы булырга омтылу күпкә максатлырак бит! Һәрхәлдә, Георгий Ибушев соңгы егерме еллар эчендә татарның асыл җырларын, көйләрен халыкка җиткерүдә, эстрада елъязмасында бер якты сәхифә булдырды. Аның җырлавында сүз аша көйнең матурлыгы ачыла, көй аша сүзнең мәгънәсе зурлана.

Артистлар, гадәттә, хискә бай, сүзгә тапкыр булсалар да, араларында үз сәнгатьләре, эш-хезмәтләре турында уй-фикерләрен кәгазьгә төшерә алучылар сирәк. Ә бит инанган идеалыңа ирешү өчен, үз сүзеңә, эстетик принципларыңа иҗтимагый яңгыраш биреп, аны киң җәмәгатьчелеккә ирештерү – кирәк һәм мактауга лаек шөгыль. Г.Ибушев моны яхшы белә, һәм сүзе, көе, шигыре, гомумән, бар гамәле белән шушы юлда туктаусыз хәрәкәттә».

Һәм менә, ниһаять, җырчының шигъри иҗатын туплаган китап. Җырчы шигырь китабы чыгара. Шәп бит! Сүз тәмен тойган кеше җырны ничек иттереп җырлыйсын (сүзне бүтәннәргә җиткерү җәһәтеннән әйтәм) белә булыр инде ул! Мин Г.Ибушевның шигырьләрен анализларга җыенмыйм. Укучы үз бәһасен бирер. Ә аның, Татарстан халык артистының, үз шигырьләренә карата фикерләрен белеп тору да кызык. Миңа җибәргән язмасында ул болай ди:

«Мин күп язмыйм, елына 15—20 шигырь. Аларны да күбесенчә көз ахырыннан апрельгә кадәр генә язам. Шигырьләремдә тормышның төрле якларын чагылдырырга тырышам. Аларда кешелек язмышы, мәхәббәт, табигать матурлыгына соклану, тугрылыклык, хыянәт, гомер турында уйлану... Иҗади кыйблам – табигатькә соклану. Кешеләргә тирә яктагы (әле без юк итәргә өлгермәгән) матурлыкның гаҗәеп серлелеге, чисталыгы турында сөйлисем, аларга ул тере табигый матурлыкны тоярга, аңларга ярдәм итәсем килә.

Шигырьләремдә авыл темасы зур урын алып тора. Авыл ул миңа көч, илһам биреп торучы тере чишмә. Авылның зеңгелдәп торган рәшәләрен, йомшак моңлы кичке эңгерен, кышкы бураннарын, төнге яңгырларын, ачык йөзле, киң күңелле кешеләрен яратам. Авылда мин күңелемә, кышын язылачак шигырьләрем өчен, шомыртларның шавын, чишмәләрнең чыңын, тургайларның җырын, таңнарның алсулыгын, төнге ялгыз тальян моңын җыям. Ләкин мин үземне һөнәри шагыйрь дип атарга җыенмыйм, мин җырчы, ә шигырь – җанымның бер өлеше. Әгәр дә шушы шигырь дигән чиста, татлы өлешне җанымнан алсаң, мин бөтенләй башка кеше булып, тавышым да, җырлавым да төссезрәк, моңсызрак булыр иде».

Бу юлларны укыгач, шагыйрь җанлы җырчыга уңышлар гына телисе кала.

*Равил Фәйзуллин*
*Декабрь, 2006*

**И ҖЫР ГЫНАМ, ҖЫРЫМ...**

Ерактан, бик ерактан акрын гына бер җыр агыла. Аһ, бу нинди йөрәк өзгеч моң?!

Кайда ишеткәнем бар соң әле минем бу җырны? Нишләп әле ул минем җанымны шулай өтеп ала? Ул каядыр чакыра, дәшә, ымлый.

Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.

Күңелем сихерләнеп, моң агылган тарафка йөгерәм. Ул – якында... Бәгырьләремне телгәли, елыйсыны китерә... Елыйм, рәхәтләнеп үксеп-үксеп елыйм.

Һәр күзәнәгемне сихри наз иркәли, йөрәккә җылы нур коя. Бөтен күкрәкне тутырып, тирән итеп сулыш алам да: «Син кем, син кем?» – дип өзгәләнеп кычкырып, уяныр китәм.

Карале, күзләремнән һаман яшь ага.

Безнең ил – уйнар, көләр җир, –

дип җырлаган матур йомшак тавыш бөтен Ястык урамын, югары очны чорнап алган. Яшьле күзләремне учларым белән угалап алам да, ниндидер бер булачак могҗизаны кабул итеп алырга әзер булган кебек, шушы моңлы агымга ияреп китеп барам.

Әй, язмыш, рәхмәт сиңа бу төнең өчен! Рәхмәт сиңа дүрт тәрәзле, җилкапкалы, салам түбәле өең, шул өйнең, әтинең иске тунына күмеп йоклаткан өйалдысы өчен!

Рәхмәт сиңа! Шыгырдап торган нык бүрәнәләрдән салынган зиннәтле өй эчендә, мамык юрганнарга чумып ятсам, миңа бу сихри аһәң кагыла алган булыр идемени? Мин аны ишетеп, төшләнеп, үксеп уяныр идемме? Юк, җыр, төнге тынлык аша болын-тугайларга китеп таралып эрер яки кемнедер, башканы сайлап кагылып, назлап үтәр иде. Җыр, шушы төнне син мине иркәләп, ап-ак канатларың өстендә тибрәтеп, нәни җаныма, үзем дә аңлап бетерә алмаслык чиста моң салып, кире кайтардың. Халкым аһәңенә төрелгән көенчә, мин ул төндә беренче мәртәбә елата торган көч барлыкны, ул бетмәс көчнең йөрәк аша чыгып, яңадан кешеләргә сафлык, моң булып, аларны чистартырга, елатырга, авыр чакта көч бирергә әйләнеп кайтуын аңладым. Бу, җыр, син идең, син...

Бөтен тирә-якны яңгыратып, шушы җырны аңлап, аны тагын да матуррак, тулырак итәргә теләгәндәй, чынлап та, сандугачлар сайрый иде. Мин үземне Ходай күктән иңдергән кодрәт астында калгандай хис иттем. Бакчадагы юкәләрдән хуш ис тарала, талгын җилдә аларның яфраклары, лепер-лепер килеп, «тыңла, тыңла» дип әйтәләр сыман иде. Мин тыңладым. Бу җыр әйтерсең лә моң ташып торган күңелдән генә чыгып калмый, бәлки, төнге күктән, Киек Каз Юлыннан күңелләргә, болын-тугайларга, урман-кырларга җылы нурдай сирпелә иде.

Рәхмәт сиңа, язмыш, син миңа шушы төнне җыр бүләк иттең. Ул гади җыр түгел, ә бәлки, якты йолдыз сыман төнне яктырта алырлык нурлы җыр иде. Күпме еллар узса да, ул җыр мине һаман үзе белән яктылыкка, матурлыкка, чисталыкка әйдәп, ап-ак нурлы канатлары өстендә алып бара. Әллә нинди мин ишетмәгән, белмәгән, бары җаным белән сиземли, тоя торган җыр дулкыннары аша ерак үткәннәргә алып чыгып җанны тетрәндерерлек борынгы җырлар белән таныштыра. Шушы җырлардан әсәрләнеп китеп, шушы моң назыннан айнып өлгергәнче, болыннарга сыймастай булып җәелгән, тибрәнеп, дулкынланып торган җырын боҗра түгәрәк уеннар эченә китереп төшерә. Миңа бала чагымнан таныш, кадерле булган Раштуа, Нардуган, Олы көн, Торойсын кебек керәшен бәйрәмнәрендә йөртә, гаҗәеп матур җырдан гына торган керәшен туйларында шушы җырларның камиллегенә, гүзәллегенә сокландырып елата. Нинди асыл җырулар җырланыла бу бәйрәмнәрдә, туйларда. Нәкъ менә шунда җырланылган җырлар туганлыкның кадерен белергә, туган җирнең бөеклеген аңларга ярдәм итә. Шушы бөек могҗиза, җырның көче, сере нәрсәдә соң?

Җыр – әниләрнең безне дөньяга китергәндә кычкырган изге тавышы ул.

Җыр – таңнарның алсулыгы, чыкларның җемелдәве ул.

Җыр – сабыйларның көлүе, төркем-төркем күперенеп килгән ап-ак болытларның агымы ул.

Җыр – «сөям» дигән серле пышылдау, иреннәрнең иреннәргә кагылгандагы назы ул.

Җыр – җылы дулкын булып игеннәргә сарылган рәшә чыңы, чишмәләрнең челтерәве ул.

Җыр – серле төндә йолдызлар булып коелган керсез карларның аклыгы. Киек Каз Юлларыннан иңгән яктылык ул.

Җыр – минем, синең ярсып типкән йөрәк тибеше, халыкларны азатлыкка чакырып дәшкән көчле аваз ул.

Җыр – ятимнәрнең күз яше, тормышта адашканнарның, чит җирләрдә юксынганнарның сагышы ул.

Җыр – халыкларны халык иткән, аларны бер-ләштергән, һәрберсенең үзенә генә хас төсмере ул.

Җыр – язгы җылы яңгыр астында хуш ис бөркегән сирень, шомыртларның шавы, кеше җанының бетмәс-төкәнмәс матурлыкка, чисталыкка, кешелелеккә, изгелеккә ия булырга тиеш икәнлеген дәлилләүче бөек рух ул.

Җыр – берни белән дә чагыштырып булмаслык, Ходай кешеләргә бәһасез җан авазы итеп иңдергән изге моң ул.

Әгәр дә мин өздереп, җыр менә шушы инде ул, дисәм, минем белән килешеп ризалашып бетмәүчеләр дә аз булмас иде. Чөнки җырны аңлаган, яраткан һәр кешенең җыр турында үз фикере, үз сүзе бар һәм бу бик дөрес тә, чөнки җыр бит ул – тере нәрсә, җан моңы. Шуңа күрә аны һәр җан үзенчә аңлый, үзенчә кабул итә.

Җыр ничек туа соң? Мин композитор түгел, ләкин, минем сиземләвем буенча, чын җыр бик тә бәхетле чакта, яки өзелеп юксынганда, нәрсәдәндер кинәт кенә күңел нечкәреп, ташып киткән чакта туадыр. Җыр болай гына бер сәбәпсез тумыйдыр ул.

Тукта, җыр языйм әле, дип кенә җансыз язылган җыр чын җырдан бик ерак тора. Чөнки иҗат вакытында була торган ләззәтле бер дулкынлану, газаплану, тойгылар, хисләр белән сугарылмый ул җыр. Бары тик чын йөрәктән язылган җыр гына арыган күңелгә җиңеллек китерә, җанны чистарта, көрәшкә дәшә, матурлыкка ишек ача. Зур, чын җыр иксез-чиксез көчкә ия. Ул таныштыра, кавыштыра, авырудан дәвалый, хәтта бер-берсен дошман күргәннәрне дә татуландыра, елата, юата.

Чү, тыңла, ишетәсеңме? Миллионлаган аналар тавышы Җир шарын уратып алган. Күпме телләрдә тибрәлә өмет катыш бу тавыш. Бәхет теләп җырланучы бишек җыры ул. Һәр бишек, гөнаһсыз сабый янында ап-ак канатларын кагып, һәрбер нәни йөрәккә кагылып алырга омтыла. Күр-күр, әнә кечкенә генә шушы зат әнкәсенең күкрәгеннән иреннәрен алган да, бишек җыры астында йокымсыраган килеш елмаеп куя. Күр, ул башын ничек матур итеп артка ташлаган, ә алсу яңагы буйлап әкрен генә ап-ак сөт тамчысы тәгәрәп төшеп бара, тагын бер мизгел – шушы тамчы тып итеп каядыр төшәр дә бөтен Җир шарына без аңламый, ишетми торган телдә җырга рәхмәт әйтер, чыңлап куяр. Әй, керсез нәни йөрәк, шушы чыңны югалтмыйча саклап кала алырсыңмы син? Еллар үтү белән безнең бу тормыштагы ялган, ялагайлык, акчага, чүпрәккә сатылу синең йөрәгеңдәге бу нурны сүндермәсме? Сүндермә син ул

нурны, сүндермә! Ул сине «Әллүки»ләргә, «Тәфтиләү»ләргә алып чыгар, «Безнең ил»ләре, «Кара урман»нары белән иркәләр. Җирдә ялганнан, пычрактан башка Матурлык дигән тагын бер төшенчә – җырлы, моңлы, кешелекле дөнья бар әле. И җыр гынам, нигә без, кешеләр, бу дөньяга Матурлык җыярга туасы урынга, бер-беребезгә шулкадәр күп әшәкелек эшләргә киләбез?! Бер уйласаң, без бу дөньяга кунакка гына килгән бит. Шушы мизгелдә бер-беребезгә әйтерлек җылы сүзләребез юкмыни соң? Күзгә күз карашып, назлы сүзләр әйтеп сөешерлек намусыбыз да калмаганмыни инде? Әй, сабый, кичер мине мондый сүзләрем өчен! Җирдә бөтен нәрсә дә нурдан, изгелектән генә тормый шул әле. Кеше җанын каралтырга, түбәнсетергә, таптап узарга әзер торган күп әшәкелек, гаделсезлек бар җирдә. Ләкин син күңелеңә әнкәңнең бишек җыры аша кергән шушы изге нурны сүндермә, югалтма! Шушы нур, якты маяк булып, бөтен гомерең буена җемелдәп, алга – матурлыкка, камилләшүгә таба дөрес юл күрсәтеп, чакырып торыр. Син курыкма гына, курыкма! Алга – яктылыкка бар, камилләшүгә таба – кешелеклелеккә атла. Әгәр дә син кешене кеше итүдән туктатучы шушы караңгылыкны узып, яктылыкка чыга алсаң, үзеңнең кеше дигән бөек исемеңә лаек булырсың. Азмыни әле, бүген шушы караңгылык эчендә адашып, буталып беткән, «без – милләтнең аңы, җаны» дип кычкырырга яраткан, бер-берсе белән тарткалашып арыган шагыйрьләр, язучылар, «милләт өчен көрәшәбез» дип, теләсә кайда шар ярып йөрүче, үзен генә кайгыртучы шарлатаннар, сәясәтчеләр, галимнәр?! Алар бу караңгылыктан чыга алмаячаклар. Данга, властька, байлыкка сусау аларны күптән сукырайткан инде, күбесе нәрсә кычкырганын, ни теләгәнен үзе дә аңлап җиткерми. Менә нәкъ шундыйлар аркасында җирдә милләтләр арасында ызгыш-сугыш чыга, тетрәнүләр була. Чөнки алар әнкәләре бишек җыры аша күчергән нурлы маякны күптән сүндергәннәр инде. Ләкин иң авыр чакта «килеп терәлдем», «беттем» дигәндә генә, иң кешелексез җан да, әгәр дә мөмкинлек бар икән, мәрхәмәтлелеккә сыенырга омтыла. Инстинкт буенча булса да, беренче җырның – бишек җырының яктылыгын эзли. Беркемнең дә җирдә җылылык эзләп, таштай, салкынлык бөркеп торган җанга сыенганы юк бит әле. Шулай булгач, «кешелеклелек, изгелек, матурлык дип сөйләнү – әкият ул» дип әйтүчеләр тагын бер кат ялгышалар, чөнки аларның үзләренә үк җылысы җитми.

Оч, җырым, оч! Ап-ак канатларыңны җилпеп-җилпеп ал да, бу тормышта адашып, аптырап беткәннәр, дөреслеккә сусап та аны таба алмыйча өметсезләнгәннәр, матурлыкка, гүзәллеккә омтылганнар күңеленә якты нурыңны сирпе. Көчсезләнгәннәргә – терәк, адашканнарга – маяк, өметен җуйганнарга өмет бир. Бөтен тирә-якта гаделсезлек тулып яткан шушы дөньяда Матурлыкка алып чыгучы нурлы юлыңны күрсәт. Юк, бу кеше нәфесен канәгатьләндерү өчен түгел, ә бәлки, кешенең эчке дөньясын баетуга алып бара торган юл. Кеше җанының чисталыгы, сафлыгы байлык белән дә, дәрәҗә белән дә үлчәнми, аны сатып алып та, алыштырып та булмый, ул һәркемгә кылган гамәлләренә, намусына карап бирелә. Юк, бу һич кенә дә кеше затлы киенмәскә, мул яшәмәскә, иркен йортларда тормаска тиеш дигән сүз түгел! Намуслы тырыш хезмәт белән эшләп тапканны кияргә дә, булган белән горурланырга да мөмкин. Ләкин мал колы булырга ярамый. Чөнки җан кол булу өчен яратылмаган. Юк, мең тапкыр юк. Җан изгелек кылу, матурлыкка омтылу өчен яратылган лабаса. Җан, әнкәсе кулында оеп, башын артка ташлап йоклап киткән сабый кебек керсез булып туа түгелмени? Хәтерегездәме, алсу яңак буйлап тәгәрәп төшеп баручы ап-ак сөт тамчысы? Кешегә көч бирүче изге тамчы, тере тамчы ул. Ана күкрәгеннән чиксез сөю белән баласына бирелә торган бу тамчыда өмет, ышаныч тулы. Бу – үзе матур җыр. Җыр гына да түгел, ә бәлки, җан, күңел ачкычы. Балачак хыялларын, чисталыгын, җылылыгын, хәтта балалыкның үзен дә аз гына булса да саклап кала алган күңелләргә ул тамчы зың итеп килеп кагылыр да, нурлы юл буенча әйдәп, Матурлык иленә ишек кагар.

Атла син бу юл буйлап. Матурлык, гүзәллек, моң, җыр иленә керергә лаексың. Син түгелмени ул, ата-ананы хөрмәт иткән, кайда һәм кем булсаң да, кече күңелле, кешелекле булып кала алган кеше?! Таныш булмаганга абынганда кулын сузган, бер телем икмәкне урталай бүлешкән, чит кайгыны уртаклашырга ашыккан, зур булмаган шатлыкка да чын күңелдән сөенә, шатлана белгән кеше син түгелмени ул? Син. Син ул. Матурлыкка омтылган, бишек җыры кабызган якты, җырлы маякны сүндерми саклаучы изге күңелле кеше. Шушы маяк сине караңгылык аша комсызлыктан, кешелексезлектән, җанны данга һәм дәрәҗәгә сатудан саклап калды, Гаделек, Матурлык, Җыр иленә алып чыкты. Күрәсеңме, шифалы нурларын чәчеп, дөньяны иркәләп кояш күтәрелеп килә. Болын-кырлар өстендә рәшә дулкыны уйный, нидер көйли, җырлый. Узган төннең кара-кучкыл дулкыннары офык читенә кереп күмелә, югала. Күр бу матурлыкны, җыр әнә шулай туа.

Уяна иркен болыннар,
Ачыла гөл керфекләре, –

дип кычкырып җырлыйсы, гүзәл табигатьнең иртәнге җырына кушылып, моң булып эрисе килә. Әнә ул җыр, утлы тамчы булып, гөл керфекләре өстендә яна. Җил уйнап узар да, бу тамчылар, бәллүр чыңыдай бер-берсенә кагыла-кагыла, җиргә сибелерләр. Кем белә, бәлки, бу чың таң җырының

кушымтасы булыр. Әнә җыр үзәннәр өстендә, үтә күренмәле җиңел япма булып, әкрен генә дулкынланып ята, ә йомшак җил, шаярырга теләгәндәй, шушы купшы япманың бер читенә кагылып ала да, сылу яшь каеннарның бөдрәләрен капларга теләгәндәй, шушы аклыкны үзән читенә таба ияртеп алып китә.

Җыр кешене матурлык алдына китереп бастыра: күзең бар икән, күр, җаның бар икән, той. Матурлык бу үр, ерактагы офык чите белән генә чикләнми. Ул чиксез, бертуктамый үзгәреп, яңгырап тора. Шуңа да шагыйрь:

Үрләре дә зәңгәр дулкын-дулкын,
Ул үрләрнең чиге кайда соң? –

дип юкка гына хозурланып, ләззәтләнеп язмаган. «Ул үрләрнең чиге әнә монда, якында гына», – дип әйтелсә, җырның кыймммәте югалыр; ул тәмамланмас, кешене уйландырырлык көчкә ия булмас иде. Җырның бөеклеге шунда ки, ул һәркайсыбызны үз дулкынына алып, без күрмәгән зәңгәр үрләр артындагы матурлык дөньясына илтә, Җир-ананың йөрәк тибешен тоярга ярдәм итә. Якты хыяллар, яңа хисләр, тойгылар эченә урап ала. Җыр яңгыраганда гына иң бөек көченә ия. Җыр – кәгазьдә ноталы тамга, ә күңелдә бикләнеп ятканда җылы тойгы гына, кеше күкрәгеннән ургылып чыкканда исә сүз, көч, моң, яктылык ул. Күңелендә аз гына кешелеклелек хисе сакланып калган булса, таш бәгырьне дә эретерлек, аңа җан өрерлек көче бар аның. Җыр кешене туганда бишек җыры булып каршы ала, көчлеләр җанын үлем аша үлемсезлеккә алып чыга.

Ләкин җыр уенчык түгел, җыр белән уйнарга-шаярырга ярамый. Юк, сүз бүген көннәр буе яңгырый торган вак-төяк җырлар турында бармый. Алар ялтыравыклы уенчыкларны гына хәтерләтәләр. Без бүген җыр дип, ни сүзе, ни көе булмаган йөзләрчә бер-берсенә охшаган уенчыкларны атый башладык. Ни өчен уенчык, ә җыр түгел соң? Чөнки алар яшәр өчен тумаган. Без алар белән вакытлыча уйныйбыз гына. Берничә айдан инде аларның беркемгә дә кирәге калмый – алмашка яңа төрле бизәкле уенчыклар килә. Шыгрым тулы залларда җырланыла торган буш сүзле, чиле-пешле җыр дип атала торган гарип көйләрне тыңлап, эреп-оеп утыручы зыялыларыбызны күреп кызганам мин. Җырны уенчыктан аера башларга вакыт түгелме? Әлбәттә, вакыт. Бүгенге көндә зыялыларыбызның күпчелеге иң гади җырдан, такмактан тәм табып, катлаулырак, эчтәлеклерәк җырны кабул итәргә әзер түгел икән, гади халык турында нәрсә әйтергә мөмкин соң? Без үзебезне шушы мескен хәлгә тартып төшердек. «Зөлхиҗә»не, «Гөлҗамал»ны, «Уел»ны, «Рәйхан»ны халык күңеленә ирештерерлек ничә генә бөртек җырчыбыз бар соң? Ләкин ул җырлар яңгыраган вакытта да бик күпләрнең аларны ахырына кадәр тыңларга түземлеге җитми. Без моңлы, эчтәлекле җырны тыңлаудан бизә барабыз. Әйе, андый моңны кабул итү өчен аз гына уйланырга, күңелне ачып, аңа үтеп керергә, җырчыны хөрмәт белән тыңларга өйрәнергә кирәк. Без бәгырьнең түреннән, йөрәк аша ургып чыккан бу изге аһәңнең җан авазы икәнен оныттыкмы әллә? Тыңлыйк әле, ул тере, йомшак авазны. Бу аваз кешене таң калдыра, көтмәгәндә генә биеклеккә омтыла, тәннәрне чемер-чемер китереп ала, сандугач кебек җилпенергә, сайрарга тотына, йә булмаса, киң Идел сыман тулып, салмак кына агыла башлый. Яки көтмәгәндә генә, җылы май кичен искә төшереп, шундый тыныч, үтә күренмәле нур сыман эленеп кала. Кеше тавышы иң затлы уен коралларыннан да матуррак, нәфисрәк. Чөнки аның кыллары җан шул. Ә җан кояшлы, моңлы, назлы, кирәк икән нәфрәтле, көчле һәм горур ул.

Ләкин бүген булыр-булмас, карлыккан, «дерек-мерек»ләп торган тавышларны йолдыз дәрәҗәсенә күтәреп, данга күмделәр. Күпме тавышың булмаса, шул кадәр яхшырак. Әгәр дә селкенә, ритмга өлгерә алсаң яки чыш-пыш итеп моң чыгара белсәң, син – йолдыз. Әйе, җирдә йолдыз белән тиңләрлек гүзәл тавышлы җырчылар да бар. Алар үзләренең тавышлары, иҗатлары белән үзләрен генә түгел, Ватаннарын да данлыйлар, зурлыйлар. Әмма нигәдер безнең йолдызларның ни нуры, ни тавышы калын кесәле әфәнделәр яныннан еракка китми. Без С.Сәйдәш белән Р.Яхинны аңламаслык дәрәҗәгә төшеп җи-түебезне сизми дә калдык. Кайберәүләр: «Дөрес түгел», – дип кычкырырга ашыгырлар. Юк, дөрес, йөз кабат дөрес. Бүгенге тамашачыны вак-төяккә күнектерделәр. Ул сәхнәдән бик еш ишетелә торган пычрак, әдәпсез шаяруны, шау-гөр килеп, кул чабып кабул итә. Шуңа күрә дә бүгенге көндә сәхнәгә арзан җыр белән бергә шакшы юмор үтеп керде. Боларның барысы да халыкның зәвыгын төшерүдә зур роль уйныйлар. Радио, телевидениене сәнгатькә өч тиенлек тә катнашы булмаган тавышсыз, талантсыз җырчылар басып китте. Әгәр дә без шушы юлны сайлап, сәнгатебез шушындый булырга тиеш дибез икән, безнең бик тиздән кыргыйлар хәленә төшүебез мөмкин. Менә шуңа күрә дә талантлы чын сәнгать әһелләрен дәүләт үз канаты астына алырга тиеш. Шулай булганда гына, вакытында җырчыга бәя бирә белгәндә генә талант үсә, ныгый ала, чөнки җырчыга зур югарылыкта җырлау өчен бирелгән вакыт бик аз ул. Без чын талантлы шәхесләрнең милләтебезнең йөзек кашы, горурлыгы, рухи байлыгы икәнлеген онытып барабыз. Әгәр дә без милләт булып сакланырга, көчле дәүләт булып оешырга телибез икән, безнең бөтен яктан да нык үскән

мәдәниятебез булырга тиеш. «Кайбер күршеләребез бездән дә начаррак хәлдә бит әле», – дип уйлаучылар табылыр. Кайсы дәүләт бүген беренче булып чын-чынлап, мәдәниятkә кул сузса, шул отачак, шунда гына намуслы эш, хезмәткә хөрмәт, бер-береңә кешелекле караш, үз милләтең белән горурлану хисе, өлкәннәргә игътибар булачак. Без, милләт буларак, Р.Яхинның җыр-романсларын аңларлык биеклеккә күтәрелә алмыйбыз икән, адәм рәтле, чын дәүләт булып беркайчан да оеша алмаячакбыз. Чөнки искиткеч эчкерсез, чын йөрәктән язылган бу җәүһәр бөртекләрен аңламаган, кабул итәргә теләмәгән милләт ул югалуга, таркалуга дучар була. Милләтебезнең бу бөек улы юк инде, аның керсез, чиста җанын җыр үзенең ап-ак канатларына алып, бу исемне үлмәс җыр итеп, үлемсезлеккә күтәрде. Әмма без нинди югалтуга дучар булуыбызны бөтен тулылыгы белән аңладыкмы икән? Юк. Без, төсле җырлар белән мавыгып, милләтебезнең нинди тирән югалту кичерүен аңламый да калдык. Ләкин иң куркынычы: безнең мәдәниятебез, җыр сәнгатебез ваклана, үзенә генә хас булган йөзен җуя барган саен, кешелек үзе дә үзгәрә, мескенләнә, кырыслана. Тирән аһәңле җырларның кадере бетсә, кешенең дә кадере югала. Чөнки җыр – җан бит ул. Ә кадерсез җан башканы кадерле, җылыта алмый. Җырны талантлы кешеләр язарга тиеш, әле шулай булганда да яхшы җырлар гел туып тормыйлар. Яхшы җыр йолдыз кебек балкып туа ул, монда инде бар нәрсә дә үз урынында була. Шуңа күрә аларны классик әсәрләр дип атыйлар, һәм мондый җыр, романсларның халыкны тәрбияләүдә әһәмияте бик зур. Мондый җырлар, халыкның зур рухи байлыгына әверелеп, җыр хәзинәсенең алтын фондын тәшкил итәләр. Берничә генә шундый әсәрне искә төшереп китик әле. Н.Җиһановның «Зарыгу», Р.Яхинның «Күңелемдә яз», «Сандугач», С.Сәйдәшевнең «Әдрән диңгез», «Батырҗан җыры», Ә.Бакировның «Иртәнге серенада», Ф.Әхмәтовның «Таң йолдызы», Р.Еникеевның «Дулкыннар» җыры һәм башка әсәрләр. Болар безнең чын-чынлап зур байлыгыбыз, горурлыгыбыз. Без бу композиторларыбызның исемнәрен атап зур җыелышларда мактанырга яратабыз, әмма тормышта бөтенләй башкача килеп чыга. Әгәр дә алар безнең горурлыгыбыз, классикларыбыз икән, нигә аларның җыр, романсларын, опера әсәрләрен җырлаучы җырчыларның кадере юк, нигә алар эт типкесендә йөри соң? Күз буяу өчен сайлап алынган бер-ике җырчыдан башка. Нигә алар көчкә очны очка ялгап, зур кыенлыклар күреп яшиләр соң? Зурдан кубып уйласаң, җиде миллион татарга безнең ун чын тере җырчыбыз да юк бит. Әгәр дә дәүләт ун бөртек җырчысын да кешечә яшәтә алмый икән, нинди дәүләт соң инде ул?

Әгәр дә профессиональ җырчыларга караш үзгәрмәсә, без ун-унбиш елдан татар классик композиторларының җыр, романсларын югары осталык белән башкаручы җырчыларсыз калачакбыз. Бу уйдырма түгел, безнең чын-чыннан җырчыларсыз калу ихтималыбыз бик зур. Бүгенге көндә бездә Сәйдәшне, Яхинны җырлап акчалы, бай җырчы булып булмый шул. Без бүген кешенең кадере беткән чорда яшибез түгелме? Безнең җыр сәнгатебез чиле-пешле булмасын дисәк, олы җыр турында, һөнәри җырчылар турында дәүләт кайгыртырга бурычлы. Әгәр милләтнең хәзинәсе, горурлыгы булырга тиешле матур тавышлы җырчы кадерсез, хәерче хәлендә икән, без киләчәктә яңа яшь сәләтләр туар, милләтнең олы җырын биеклеккә күтәреп башка халыкларга да ирештерер, ишеттерер дип өметләнә алабызмы соң? Юктыр. Әгәр дә синең иҗатың, талантың кирәк дип табылмый икән, кадерсез җиргә нәрсә өмет итеп килергә кирәк?!

Җыр – кеше фикерен матур, нечкә итеп җиткерүче иң гүзәл, иң югары нокта ул. Без тормышта бер-беребез белән гади сөйләм телендә аңлашабыз. Күтәренке, саф хисләребезне шигъри юлларга күчерәбез. Ә инде шигъри тел белән дә аңлатып булмаган нечкәлекне бары тик җыр гына күңелләргә җиткерә ала. Шигырьдәге сүз ничек кенә көчле булмасын, ул әле матур, мәгънәле сүз генә. Әгәр дә шушы көчле сүзгә талантлы көй кушылса, җыр барлыкка килә. Җырның тәэсир итү көче сүзнекенә караганда күпкә көчлерәк аның. Телнең терәге һәм бизәге – җыр. Җыр барда тел, халык бар. Олы җырны башкарырлык җырчыбыз, аңларлык халкыбыз калмаса, ап-ак канатлы җыр бездән китәр. Ә милләт моңсыз, җырсыз яши алмый. Ләкин безнең җыр сәнгатебез гел моңлы, елак җырлардан гына торырга тиеш түгел, моңга гына салынып сагышланып ятсак, без бөтенләй йомшап, җебеп бетәрбез. Безнең җырларыбыз моң, сагыш белән бергә, күтәренке рухлы, тирән эчтәлекле һәм яңгырашлы булырга тиеш. Андый җырлар күбрәк булса, без үзебез дә җаныбыз белән чистарынып, яктырып, сафланып китәрбез. Менә ни өчен җырга бары тик күңел ачу өчен генә тудырылган нәрсә итеп карарга ярамый. Җырны аңлау өчен югары уку йортын тәмамлау кирәкми, ул безгә тумыштан бирелгән. Шуны тоя, ишетә белү генә зарур. Тыңла да җый: каеннар шавыннан, тургайлар җырыннан, кичке эңгердән, болын гөленнән – бары да җыр бит. Каеннарга сөеп, гөлләргә назлап карарга өйрән. Каенга бары тик буласы утын, болын гөлләренә, яшел хәтфәсенә печән итеп кенә караудан узмасак, ничек күңел матурлыкка омтыла алсын ди?! Матурлыкны тойган күңел генә яхшыдан начарны аера белә. Ә яхшы җыр безне олы музыка дөньясына алып чыгар, опера, симфония, балет белән таныштырыр. Бу өлкәдә белгечләр булмасак та, зур сәнгатькә җан белән кагылып алу бәхет түгелмени? Почмактагы чаршау

читеннән генә карап, «Сәнгатьнең бу төре безгә кирәкме, юкмы», – дип ятсак, «Безгә мөнәҗәттән башка берни дә кирәк түгел», – дип әйтүчеләр дә табылыр. Ә зур сәнгать ул диңгез кебек. Шул диңгезгә курыкмыйча керсәк, башка халыкларның да күңел хәзинәсе белән танышырбыз. Күңелдә сакланып калган бишек җыры безне моң дәрьясына алып керсә, зур сәнгать дөньясына да юл ачылыр.

Ап-ак канатларыңны җилпеп-җилпеп оч, күңелләргә өмет, ышаныч бир, җыр! Безгә, кешеләргә, бәхет, тугрылык, сөю, матурлык турында җырла! Матурлыкка, чисталыкка сусаган җан шушы серле дөньяга тартылып торсын.

Олы җыр – сер дә әле ул. Беркайчан да ачылып бетмәячәк татлы сер. Җырның тагын бер бөек көче – аның серлелегендә. Менә шушы серлелек башкаручы йөрәге аша узып таныш, бик тә таныш җырга да яңа яңгыраш, яңа бизәкләр өстәп, таң калдыра, кешедә ләззәтләнү, рәхмәт хисе тудыра.

Рәхмәт сиңа, җыр, рәхмәт! Синең телеңне, әйтер сүзеңне аңлый алу зур бәхет ул. Бәхет ул – яраткан эшеңдә, сәнгатьтә горурланып, чиста намус белән кеше күзенә карый алуда, үзеңне кеше итеп тоюда һәм күңелеңдә син йөрткән олы җырда.

**ҖӘЙ АХЫРЫ**

Өмет белән яши торган көннәр,
Мул, бай вакыт – җиткән җимешләр.
Алмаларга татлы су йөгергән,
Алар алсу, алтын кебекләр.

Гаҗәеп чак, бар да катыш монда,
Яңа сөргән җирләр кап-кара.
Ә бер якта әле сугылмаган
Көзге бодай җилдә чайкала.

Көннәр үзгәрүчән – әле җылы,
Кызу булып ала берара.
Йә эш өзеп, берничә көн буе,
Яңгыр ява, кояш югала.

Кыр гөлләре уңып аланнарга,
Үзәннәргә моңсу төс кертә.
Тупыллардан берән-сәрән төшкән
Саргылт яфрак – адым ул көзгә.

Җәй ахыры, никтер уйчан вакыт.
Муллык белән торса да тулып,
Такыясын салган болыннарда
Ромашкалар калган боегып.

*20.11.1993*

**МИЛӘШЛӘР**

Җәйләр үтеп бара, миләшләрнең
Куе кызыл инде тәлгәшләре.
Юк, алданып өзмә! Алар әче,
Салкын өтсен әле миләшләрне.

Төшсен әле кырау, ак бәс булып,
Алсын төреп миләш тәлгәшләрен.
Ут тамчы күк тамсын аннан кырау,
Әчелеген алып миләшләрнең.

*8.01.1999*

**АЛМА КОЕЛГАН ТӨНДӘ**

Коела әнис алмалар,

Сибеп чык бөртекләрен.
Сискәнә төн, ә син, күңел,
Нишләдең, әйт, нишләдең?

Йоклатмый мине, йоклатмый
Алмалар тупырдавы.
Еракта ялгыз тальянның
Өзгәләнеп уйнавы.

Йөримен төнге бакчада,
Хыялга, уйга чумып.
Гомернең узган елларын,
Яшьлегемне юксынып.

Коела минем алмадай
Чынга ашмас хыялларым.
Утырам тыңлап бакчамда
Алмалар тупырдавын.

*29.08.2004*

* * *

Бөтерелә су өстендә сары яфрак –
Көзләр төсе, көзләр моңы агылган чак.
Миләшләрнең тәлгәшләре утлы күмер,
Урман гүя очкын чәчә кочак-кочак.

Яфрак түгел, безнең язмыш мәллә суда?
Дулкын кагар аны шулай уңга-сулга.
Еракмы ул китеп туктар, якынгамы?
Һәркемгә дә нидер язган язмышына.

Вакыт ага ашыкмыйча көзләр аша,
Кырпак кырау әле эри, тагын ята.
Инеш чите челтәрле боз иртәләрен,
Үзәннәрдә куе булып томан ята.

Күңел чиста, юк бернинди сагыш хисе.
Әйтерсең лә томаннардан сеңә аклык.
Казлар оча, кыр казлары, тезелешеп,
Тавышлары әллә сагыш, әллә шатлык.

Карап калдым озак кына артларыннан,
Авазлары үзәннәрдә калды эреп.
Мин үзем дә югалдым күк шулар төсле,
Көзге әкият кочагына килеп кереп.

*17.05.1994*

**КҮЛӘГӘЛӘР ДӘ ТӨСЛЕ!**

Йөргәнең бармы урманда,
Кояшлы аланнарда:
Өрәңгеләр уттай кызыл,
Кып-кызыл баланнар да.

Усакларда утлы балкыш –
Кай ара кызарганнар.
Миләш яфраклары куе
Шәфәкъ төсен алганнар.

Каеннар купшы, аһ итеп
Куясың матурлыкка.
Имәннәр кызгылт көйгәләк,
Горур басып тынлыкта,

Лепер-лепер серләшүче
Усаклар гамен тыңлап,
Торалардыр кебек оеп,
Җиңелчә йокымсырап.

Көзге урман балкып торган
Илаһи җәйгор төсле.
Нинди генә төс юк монда –
Күләгәләр дә төсле!..

*10.03.1998*

**КӨЗГЕ МОҢ**

Тагын көз, тагы каеннар
Моңсу төсләре белән
Ямь-яшел булып утырган
Уҗымнардан көнлиләр.

Тагын көз, инеш өстендә
Әйләнеп яфрак йөзә.
Салкын, тын, аяз көзге төн
Җиргә ак кырпак сибә.

Тагын көз, сизми калынган:
Миләшләр утта менә.
Ах, бу вакыт әйләнеше
Әйтерсең мизгел генә.

Нәрсәдер әйтәсе килә:
Сагыш, моң җанга тулган.
Тагын көз, никтер ямансу
Торналар тавышыннан.

*30.08.1989*

**КӨЗГЕ БАКЧА**

Көзге бакча буш һәм тыныч,
Өрәңгеләр ут төсле.
Шәһәр шавы монда тонык,
Яфрак сарган юл өстен.

Шул юл буйлап ялгыз киләм,
Тыңлап яфрак авазын.
Көзге сафлык белән тулып
Торган чагы һаваның.

Җил, уйнаклап, каеннардан
Сап-сары яфрак чәчә.
Юкәләр тын, өрәңгеләр
Миләшкә нидер дәшә.

Ә миләш кызара, яна,
Тын гына башын иеп.
Түзәлмәдем, мин дә аңа
Дәштем, син гүзәл, диеп.

*15.10.1994*

* * *

Көзге иртә, салкынча җил
Үзәннән томан куа.
Болында, нидер уйланып,
Ялгыз ат басып тора.

Бу күңелнең була икән
Сагышлы бер мизгеле.
Торналар очкан тавыштан
Уйланып калган көне.

Каядыр китәсе килә,
Болытлар аккан якка,
Атланып, болында ялгыз
Моңаеп торган атка.

*9.10.1986*

**КӨЗГЕ ЯҢГЫР**

Көзге яңгыр, көзге яңгыр,
Салкын тамчы.
Сары яфрак,
Кызыл яфрак,
Көрән яфрак.

Көзге яңгыр сары төстә,
Кызыл төстә, көрән төстә,
Яфракларга килеп төшсә,
Кагылып үтсә.

Көзге яңгыр, озын яңгыр
Көннәр буе.
Бер туктамый җиңел шаулау
Түбәләрдә.

Көзге яңгыр минем өчен
Якты сагыш.
Уттай яфрак килеп кунды
Тәрәзәмә.

Көзге яңгыр, көзге яңгыр,
Кызыл яфрак.
Ә очында уттай тамчы
Янып тора.
Пешерер күк шушы тамчы
Кинәт кенә,
Көтмәгәндә килеп төшсә

Учыма.

*18.10.1995*

**КАЗЛАР КИТӘ**

Күрәсеңме, улым, казлар китә,
Алар шулай тезелешеп оча.
Саный күрмә, таралмасын тезем,
Саный калсаң, алар буталыша.

Ишетәсеңме, тавышлары ничек
Сагыш җыры булып ишетелә.
Без дә шулай таралыштык, улым,
Туган нигез һаман төшкә керә.

Күңел бит ул гел яз көтеп яши,
Шуның белән, ахры, алдана.
Олыгаеп килеп керәбез без
Һәр ел саен көткән язларга.

Китә казлар, гомер китә, улым,
Ап-ак канатларга уралып.
Шуңадыр да казлар киткән чакта,
Күңел никтер кала моңланып.

Гомер үтә, улым, ә бу күңел
Очар сыман булып талпына.
Казлар сыман китәр идем очып
Яшьлегемнең язы каршына.

*14.09.2001*

**БӘГЫРЬ**

Өзелеп төште
Каен бәгыре.
Өзде шул бәгырь
Минем бәгырьне.

Учыма алып
Җылыттым аны.
Узылган гомер –
Каен яфрагы.

Ул миңа нидер
Әйтте шикелле.
Кеше гомере
Яфрак шикелле.

*4.04.2003*

* * *

Каеннарга җете булып сары иңгән,
Яшел яулык төшкән шуып иңнәреннән.
Толымнары җил искәндә җилбер-җилбер,
Яфрак сибә – бу бит инде көздер, көздер.
Сизелми дә уза икән, ах, бу гомер.

*2.09.1998*

**СУКМАК**

Урман юлларында яфрак көрте.
Төсле буран урман эчендә.
Яфрак ерып юлга сукмак салам,
Юл өстендә сукмак җеп кенә.

Борылып карыйм салган сукмагыма –
Нидер калды, күңел, эзләнмә.
Гомеремнең тагы бер мизгеле
Кушылып кала шулай көзләргә.

Яфрак ява минем эзләремә,
Җил тарата төсле көртләрне.
Тормыш шулай барын күмә бара,
Хәтер кала саклап үткәнне.

Вакыт ага, шушы минутларны
Ул мизгел дә димәс, сизмәс тә.
Минем өчен төсле буран кала,
Сукмак кала сеңеп йөрәккә.

*16.04.1988*

**ӘБИЛӘР ЧУАГЫ**

Яфрак коя каен, сентябрьнең
Алтын чагы – төсләр туй итә.
Бакча читендәге ут-миләшләр
Чеметтереп җанны җилкетә.

Чолан буендагы ак мендәрләр
Нарат такталарга тезелгән.
Өсләренә каен яфракларын
Җил сипмәгән, гүя чигелгән.

Ерактагы арыш эскертләрен
Күкселлеге сарган көзләрнең.
Ә мин, җүләр, бакча артларыннан,
Тыкрыклардан җәйне эзләдем.

Кипкән әремнәргә сыенып, җәй
Ял итәдер кебек тоелды.
Ялгышасың, ялгышасың, диеп,
Сукмагыма яфрак коелды.

*25.01.1989*

**ХУШ ИНДЕ, КӨЗ**

Хуш инде, көз, тынды синең
Яфрак бураннарың.
Мин кул болгап озаттым бүген
Китүен торналарның.

Ни эзләдем болыннардан,
Бу җаныма ни булган?

Сагышлы җыр ишеттем мин
Чишмәләр тавышыннан.

Уйчанланып калды күңел,
Уңган бит тугайларым.
Хуш инде, көз, хискә тулып,
Мөлдерәп торган чагым.

*2.10.2005*

**НОЯБРЬ**

Морҗалардан күтәрелә төтен,
Ап-ак булып кырпак кар төшкән.
Төн эчендә мәлҗерәгән юллар
Беткән туңып, гүя кыш җиткән.

Су буенда каңгылдашкан казлар
Аптырашып, каткан инештә
Тая-тая, кемдер чабып киткән
Бәке авызыннан су эчә.

Ә ноябрь көлә, аңа кызык,
Ул эрисен белеп, агасын,
Болытларын ташып төннәр буе,
Вак яңгырлар булып явасын.

Әле вакыт түгел кар ятарга,
Вакыт түгел әле бозларга.
Бу бары тик – мин якында, диеп,
Ноябрьнең ишеген кыш кага.

Морҗалардан күтәрелә төтен,
Кышның күләгәсе юлларда.
Әллә ничек, башка бүген күңел,
Нидер булган бүген бу җанга.

*1.03.1998*

**КАРА КАРГА**

Кар өстендә кара карга.
Нидер чукый, нидер тапкан.
Ул беренче булып безгә
Яз хәбәрен алып кайткан.

Кар өстендә кара карга,
Түгел былбыл, түгел тургай.
Ләкин бүген, бу минутта,
Ул алардан өстен бугай.

Кар өстендә кара карга,
Елтыр күзле кара тамга.
Бит барыбер алар кайткач,
Ниндидер дәрт керә канга.

*8.04.2002*

**МИЛӘШ**

Гыйнвар, буран, авыл ап-ак.
Җил себерә карларны.
Бакчада җыймаган миләш.
Күмердәй утлы чагы.

Җил кочәйсә, очкыннарын
Чәчә миләш. Туктадым.
Үрелдем миләш таҗына,
Пешәр кебек учларым.

Учымда уттай кып-кызыл
Миләш таҗы, боз гына.
Өтте җанны, җылыт мине,
Дип әйтте күк ул миңа.

*7.02.2004*

**КЫШКЫ ТӨНДӘ**

Берьялгызым
Озын кышкы төндә,
Шигырьләрем ята
Чәчелеп өстәлемдә.
Мин йокысыз,
Йокы качты миннән.
Нидер көтәм сыман
Бүген мин бу төннән.
Минем кебек
Төн дә ялгыз бүген.
Болыт, буран күмгән
Аның айлы күген.
Карлары да аның
Җиңел, тыныч кына,
Якты эзләгәндәй,
Тәрәзәмә куна.
Берьялгызым,
Һәм мин риза шуңа.
Берни киртә түгел
Минем уйларыма.
Шигырьләрем ята
Чәчелеп өстәлемдә.
Төн, син хуҗа бүген
Минем хисләремә.

*26.12.2000*

**АВЫЛДА ЧАКТА**

Җил куа карларны,
Бөтерә, болгата.
Күңелдә яшерен
Хисләрне кузгата.

Очына бу карлар,
Тузына бу карлар.
Тәрәздә ак бизәк,
Бизәктәй хыяллар.

Кыр, болын, тугайлар

Аклыкка күмелә.
Урамнар буенча
Кар оча, йөгерә.

Җәяүле буранда,
Яшьлектә хыялда
Мин агам каядыр
Узылган елларга.

Җил кага тәрәзгә,
Кар, буран урамда.
Адаша уйларым
Көрт салган юлларда.

*11.12.2005*

**КҮКТӘ АЙ ЙӨЗӘ**

Айлы төндә, җем-җем килеп,
Карга нур сарган.
Киек казлар калдырган юл
Балкыган, янган.

Тәрәзәгә нәфис бизәк
Осталар сызган.
Әйтерсең лә тавис кошы
Затлы каурыйдан.

Соң булса да мичем яна,
Бүлмәм тын, җылы.
Урамга эңгер төс бирә
Ай яктылыгы.

Күңелнең хисләнгән чагы,
Төрле уй килә.
Йолдызларын барлап күктә
Тулы ай йөзә.

**ТӘРӘЗӘЛӘР АРТЫНДА КЫШ**

Тәрәзәләр артында кыш,
Каеннарга салкын микән?
Төн салкыны толымнарын
Энҗе сибеп бизәп киткән.

Тәрәзәләр артында кыш,
Җилләренең бар үз моңы.
Кырлар иңләп агып ята
Җил тузгыткан кар агымы.

Кая гына керми шул җил,
Актарына – нәрсә җуйган?
Тыкрыкларга киртләч-киртләч
Кар көртләре өеп куйган.

Тәрәзәләр артында кыш,
Аклык белән тора тулып.

Җанга җылы иңә сыман
Шул аклыктан, сафлык булып.

*5.01.1999*

**АГЫМСУЛАР**

Язлар җиткәч, кузгалырлар бозлар,
Болыннарга җәелеп су ташыр.
Агымсулар, язгы агымсулар
Өмет-хыялларны уятыр.

Умырзая язга кулын сузар,
Тургайлары кайтыр кырларның.
Яшьлек узар, ә ярсуы калыр
Агымында агымсуларның.

*1979*

**МАРТ**

Күзләрне камаштырып кар
Ятса да тугайларда,
Тупылларда җиңел шаулау,
Купшылык бар талларда.

Бу нинди яз, күкләр зәңгәр,
Җилләре башка аның.
Җепсәгә кунган җылысын
Яратам март аеның.

*22.11.1992*

* * *

Еракта, офыклар читендә,
Яңгыратып бер көлдең.
Аннан соң җылы җил, нур булып
Зәңгәрсу киңлеккә йөгердең.

Син узган һәр җирдә наз булып
Гаҗәеп бер сафлык таралды.
Һәркайда елмаю өләшеп
Йөрүче син идең, март ае.

*12.03.1979*

**ЯЗ**

Март бураннары башланып,
Исте дә җылы җилләр,
Челтәр-челтәр булып карлар
Тын гына эределәр.

Үзәннәргә саркып кына
Күлдәвекләр җыелды.
Челтерәп беренче тапкыр
Гөрләвек йөгереп узды.

Әле яз тыныч, оялчан,
Яшүсмер егет сыман,

Карап зәңгәр киңлекләргә
Кояшка гашыйк булган.

Ул әле ташкыннар ясап,
Белми шаулап күкрәсен.
Иркәләнеп җылы назга,
Чәчәккә күмеләсен.

*28.02.1986*

**ЯЗГЫ БАКЧАДА**

Аһ бу бакча, туйга әзерләнгән,
Асыл күлмәк киеп, күрсәнә!
Шау күбектәй шомырт, алмагачлар.
Татлы хушбуй исе тибрәнә.

Сулап туялмаслык һавасы да,
Күзне назлый торган аклыгы.
Җиңел генә алсу кершән яккан
Яшь алмагач, сылу яз кызы.

Бөтен бакча балкып, тулып тора
Чисталыктан, нурдан, аклыктан.
Кияү егетедәй торам басып,
Күкрәгемә тулган шатлыктан.

*20.11.2002*

**БӨРЕЛӘРЕН АЧА СИРЕНЬНӘР**

Шундый тыныч, иркен, рәхәт җанга,
Таллар – яшел, ап-ак – шомыртлар.
Төркем-төркем булып йөзеп килә,
Тезелешеп тау-тау болытлар.

Үрләр горур, җете ачык төсләр,
Күпреп ята кырлар, пар бөркеп.
Беренче кат күкрәү йөгереп үтә,
Япь-яшь колыннарны өркетеп.

Татлы сулыш бөркеп җир ял итә,
Аңа бүләк бүген бу гөлләр.
Җылы яңгыр яшәү көче сибә,
Бөреләрен ача сиреньнәр.

Биеклектә нурлы нәфис дуга,
Төрле төсләр белән балкыган.
Дуга түгел, язга, гүзәллеккә
Иңдерелгән затлы таҗ сыман.

*6.11.1992*

**ТӘРӘЗ ТӨБЕМ СИРЕНЬ**

Тәрәз төбем сирень, ак чәчәктә,
Татлы хуш ис – дәва җаныма.
Әллә нәрсә булды бу күңелгә,
Кырык яшькә җиткән чагымда.

Мәхәббәтем кайтты өр-яңадан,
Унсигездә кебек хисләрем.
Әллә сирень мине сихерләде,
Яшьлегемә дәшеп, нишләдем?

Ник кузгаттың минем җанымдагы
Яшеренеп яткан давылны?
Син кайтардың миңа көтмәгәндә
Шау сиреньле җылы язымны.

Мин югалып калдым, калдым каушап,
Яшьлегемә кайткан бу язда.
Син – минеке, диеп, иркәләдең,
Сусаганмын икән мин назга.

Тәрәз төбем сирень.
Ак тәлгәшләр,
Иркәләнеп, нурда коена.
Минем соңлап килгән җылы язым
Үтмәс, сулмас төсле тоела.

*6.04.1997*

* * *

Төн.
Тәрәз төбем якты.
Әллә сирень шулай
Якты бөркеп тора?
Күңелемә
Ниндидер моң тулган.
Уйларыма
Бүген нидер булган.
Йөрәгемә
Җылы сафлык тула.

Тын.
Җил талпынып куйса,
Сирень тәлгәшләре
Сүрелерләр кебек.
Әй Ходаем,
Бөртек-бөртек булып,
Ак энҗеләр
Иңнәремә минем
Сибелерләр кебек.

Ай.
Ул шундый зур,
Ә мин,
Уйларыма чумып,
Вакыт җебен җыям
Хәтер орчыгыма.

*17.05.1991*

**ТУРГАЙЛАР КАЙТТЫЛАР**

Тургайлар кайттылар
Кыңгырау чыңына

Охшаган җыр алып.
Гөрләвек җырлады
Отты да ул көйне –
Тыңладым сокланып.

Таралды язгы җыр
Болыннар өстенә,
Бәбкә үлән уянды.
Талларда ямь-яшел
Хуш исле бөреләр
Ачылып елмайды.

Алданып шул чыңга
Яшеллек уянган
Үрләргә йөгердем,
Үзем дә сизмичә,
Тургайлар җыр койган
Рәшәгә күмелдем.

*14.02.1995*

* * *

Узды яңгыр, җылы, шифа тулы –
Шомыртларның юды бөресен.
Тиздән менә ап-ак тәлгәш булып
Ачылырлар алар, күрерсең.

Ак тәлгәшләр, чайкалышып җилдә,
Хуш ис бүләк итәр һәркемгә.
Ә син шушы татлы назны сулап,
Ләззәтлек ал, сафлык күңелеңә.

Шул ук җилләр беркөн тәлгәшләргә
Кагылып, үбеп сибәрләр аклык.
Сагышмы бу? Һич юк. Күңел тулы
Шомыртлардан күчкән чисталык.

*22.02.1998*

**ЯЗГЫ КӨНДӘ**

Язгы матур көндә
Камышлы саф күлгә
Пар аккошлар төште,
Сафлык иңгән төсле.

Без дә икәү – бер пар,
Күлдәге пар кошлар,
Кагындылар уйнап,
Безгә бәхет юрап.

Тибрәп куйды күл дә,
Елмайгандай безгә.
Ак шомыртлы яр да
Тулган сөю-назга.

Без бәхетле идек,
Пар аккошлар кебек.

Бәхет иңгән бу көн
Бүләк безнең өчен.

*29.03.2000*

**ГӨРЛӘВЕКЛӘР ЭЗЛИМ**

Эзләнәм мин, күзлим: тирә-якта
Кайнап торган шәһәр тормышы.
Әллә ничек сәер, башка монда,
Хиссезрәк язлар сулышы.

Мин, уйланып, аулак урамнарга
Килеп чыгам – нәрсә җуйдым соң?
Гөрләвекләр эзлим, гөрләвекләр,
Шундый шаян, көмеш чыңлысын.

Авыл язын сагынам, ташкыннарын.
Тургайлары инде кайткандыр.
Инде әни, тәрәзләрне юып,
Җилләр керсен диеп ачкандыр.

Кояш төшкән якка җылы сукмак
Салынгандыр – сизә күңелем.
Зур шәһәрнең шаулы урамында
Шул сукмакны сагынып йөримен.

*8.03.1986*

**КӨНЛӘШҮ**

Дулкынланып Иделкәем
Тирбәтә көймәләрне.
Ак җилкәннәр, ак канаттай,
Талпынып куяр әле.

Акчарлаклар белән бергә
Зәңгәрлеккә юл алыр.
Мин калырмын биек ярда,
Ә Идел дулкынланыр.

Ярсып тибәр шунда йөрәк,
Карап ак канатларга.
Эх, әйләнә алсам иде
Җитез акчарлакларга!..

Җилпенеп куяр идем дә,
Кагып ак канатларны,
Куып җитәр идем кебек
Ап-ак акчарлакларны.

*4.10.1994*

* * *

Кичке эңгер, бакчаларга иңеп,
Шомырт тәлгәшләрен үпкәндә;
Дулкын-дулкын булып татлы һава
Үзәннәргә агып төшкәндә;
Инеш өстен үтә күренмәле

Җиңел томан урап алганда;
Бөдрә толымнарда тибрәнергә
Сандугачлар кунгач талларга;
Сиздермичә, төн карасы, куерып,
Офык алсулыгын күмгәндә;
Бер-бер артлы затлы бизәк булып,
Күккә нурлы йолдыз иңгәндә –
Җиңел шаулау сыман калтырану
Йөгереп үтә бөтен тән аша.
Җан, талпынып, эңгер, шомырт, томан,
Йолдызларга барып тоташа.
Әйтерсең җир коча, иркәли күк,
Күреп тоялганга бу назны.
Шушы гаҗәп гүзәллеккә кушылып,
Олы сөю урый җиһанны.
Ул күкләргә, йолдызларга җитеп,
Әкрен генә таңны уята.
Шомырт тәлгәшләрен үбә-үбә,
Тагын эңгер төшә, таң ата.

*18.04.2002*

**ДУЛКЫННАР**

Җил исте,
Йөгерде дулкын,
Шаярып какты ярга.
Сокланып,
Сөеп, көнләшеп
Карыйм шул дулкыннарга.

Тәгәрәп,
Көлеп, чәчрәп,
Бер-берсен куып, алар
Әллә соң
Миңа яшьлекнең
Сәламен тапшыралар?

Булды ла
Сезнең шикелле
Минем дә ярсу чагым.
Ярларга,
Язгы ташкындай,
Сыймыйча ташыганым.

Дулкыннар,
Шаулагыз, шаула!
Мин аңлыйм, тоям сезне.
Дәрт биреп,
Каядыр алга
Дәшәсез йөрәгемне.

Тынмаска,
Һаман ярсырга,
Эзләнергә, табарга!
Йөрәгем
Сездәй минем, дип,
Кычкырдым дулкыннарга.

*17.02.1998*

**БОЛЫТ**

Күкрәп килде болыт әллә кайдан,
Шомлы тавыш белән давыллап.
Ниндидер бер этлек теләгәндәй,
Котырынып йөрде җил улап.

Эңгерләнеп калды көн уртасы
Тоташ килгән болыт астында.
Ишек-тәрәзләрне япты әнкәй:
«Хәере белән узсын, йә Хода».

Яшен арты яшен, тоташ күкрәү,
Өркү салды авыл өстенә.
Чалт итте дә кинәт карт тирәкне
Яшен сукты авыл читендә.

Телгәләнде кәүсә, көйде җаны,
Калтыранды тирәк, аумады.
Сыек кына яңгыр төшеп алды,
Күкрәп йөрде болыт, яумады.

Берни булмагандай узды болыт,
Давыл тынды, эңгер таралды.
Кинәт шунда тетрәндереп җанны,
Ыңгырашып, карт тирәк ауды.

Давыл белән күкрәп килгән көчнең
Бар ачуын алып үзенә,
Горур ауды тирәк, күренмичә
Ярсу яшен, давыл күзенә.

*29.03.1993*

**ЧЕЛЛӘДӘ**

Тау-тау булып ак болытлар калган
Онытылып офык читендә.
Кем аларны куар, җилләр качып
Киткән мәллә дөнья читенә?
Шундый кызу, бөркү, тын алырга
Күләгәдә хәтта юк һава.
Нур түгелдер, әйтерсең лә күктән
Көлтә-көлтә булып ут ява.
Әлсерәгән үрләр, рәшәләрдә
Хәрәкәтсез калган эленеп.
Чү! Кинәттән тонык кына күкрәү
Үзәннәрдән үтте йөгереп.
Офык читендәге тау болытлар,
Без бит монда, монда дигәндәй,
Аваз бирде, тиздән җилләр кайтып,
Юлга кузгаласын белгәндәй.
Тибрәп куйды гөлләр, ә рәшәләр
Җилфердәде уйнап, зеңгелдәп.
Җиргә тере, дымлы сулыш бөркеп
Яңгыр килә иде, күк иңләп.

*12.02.2005*

* * *

Дулкын-дулкын җылы агым
Яшәү көче китергәндә,
Инде тулган бөреләрдә
Яшел чаткы күренгәндә,

Каеннарны гаҗәеп бер
Яшькелт томан сарып ала.
Талгын җилдә шушы томан
Әй кагына, дулкынлана.

Әллә нишләп куя күңел,
Сихерләнеп шушы назга.
Бөреләрдән җылы иңеп,
Яшәү дәрте күчә җанга.

Нәни генә шушы очкын
Дөрләп киткән ялкын кебек,
Талпына да, каеннарны
Яшел дулкын китә күмеп.

*17.03.1999*

* * *

Әле бу йомшак үрләргә
Кагылып аласым бар.
Рәшәләрнең җылылыгын
Җаныма саласым бар.

Чалкан ятып, биеклектән
Эзлисем бар, табасым
Тургайларның, әй, талпынып
Торган җилбер канатын.

Алар җырына үземнең
Җырымны кушасым бар.
Тирбәтсен аны иркәләп
Кырлардагы дулкыннар.

Кыңгыраулар белән бергә
Күкчәчәкләр җырласын.
Шушы тургайлы үрләрдә
Минем тавышым калсын.

Әле минем бу үрләргә
Килә бер сыенасым,
Үр гөледәй, җылы кояш
Нурында коенасым.

*25.02.1997*

**ЯЗГЫ ТАЛПЫНУ**

Тәрәзәмнән яз җилләре кереп,
Ефәк пәрдәләрне тибрәткәндә,
Ак каеннар бишек җыры җырлап,
Бөреләрен назлап тирбәткәндә,

Ашкынам мин, талпынам мин һәрчак,

Күңелем тынгы тапмый ярсына.
Йөгереп чыгармын күк яланаяк
Сабый чагым язы каршына.

* * *

Ардың мәллә, сеңлем? Утыр әйдә,
Бер ял итик шушы тугайда.
Кайтыр сукмак озын, кыңгыраулы,
Ромашкалар әнә күпме анда!

Син дә шулар кебек керсез һәм саф,
Кыңгыраулар чыңы – көлүең.
Яшьлек арыймыни – тугай буйлап
Гөлләр арасына йөгердең.

Мин сокланып карап калдым сиңа –
Ачылып килә торган миләүшә.
Ул тугайда үзе кебек керсез,
Назлы гөлләр белән серләшә.

Менә тагын без атлыйбыз бергә,
Кыр гөлләре синең кулыңда.
Әйдә, сеңлем, кыңгыраулы тавышың
Юлдаш булсын миңа юлымда.

*7.03.1997*

**ТУГАЙЛАРЫМ**

Тугайларым тургайлы,
Зәп-зәңгәр кыңгыраулы.
Әсәрләнде кинәт җаным –
Тургайлар җырыннанмы?
Кыңгырау чыңыннанмы?

Тугайларым күгелҗем –
Читтән шулай күренде.
Рәшәләрең агышында
Җаным юдым. Бир түзем.
Рәшәләрең күгелҗем.

Тугайларым чишмәле,
Суында гөлләр тәме.
Бер татысаң, гомер буе
Телеңдә калыр тәме.
Тугайларым чишмәле.

*10.05.2000*

**КҮҢЕЛЕМ ЯКЫН КҮРӘ**

Мин арышлар серкә очырганда,
Җиләк балланганда туганмын.
Яратамдыр, ахры, башакларның
Кыштырдавын җилдә шуңа мин.

Шуңадырмы, күңелем якын күрә
Урманнарның татлы һавасын.

Басуларым дымга сусаганда,
Яңгыр булып килә явасым.

Рәшә булып җемелдисем килә
Арыш кырларының түрендә.
Аҗагандай уйнаклыйсым килә
Туган якның зәңгәр күгендә.

*1978*

**КОЯШКА ГИМН**

Нур агышы, кояш чыга,
Тарала көмеш болыт.
Чишмәләрнең челтерәве
Ишетелә җыр булып.

Биектә, алсу киңлектә
Эреп сүнә йолдызлар.
Чәчәкләрне җылы бөркеп,
Үбеп уята нурлар.

Сандугач та тынып кала,
Җырын оныткан төсле.
Бер дулкын юк, алтын балкыш
Белән яна су өсте.

Кыр, болын, урман, тауларга
Җылы дулкын кагыла.
Таңны котлап биеклектә
Җырлап тургай кагына.

Ачыла ерак киңлекләр,
Нурга нур кагылып чыңлый.
Җир илаһи яктылыкта
Кояшка гимн җырлый.

*22.01.2002*

**ТАУ ЕЛГАСЫ**

Салкын, саф елгалар була,
Таулардан ургып аккан.
Суларын ярсып кыялар
Өстеннән аска аткан...

Шаулап, кайнап, күбекләнеп
Раслый дәрман барлыгын.
Таулардан горурлык алып,
Ул җырлый таулар җырын.

Ашыгып, сулары белән
Бәрелеп таш ярларга,
Чылтырап көлеп җибәрә,
Көч сиздерә алганга!

Йә кинәт кубарып алып
Колач җитмәс ташларны,
Кочагында бөтереп йөртеп,

Ярларга бәрә тагы.

Әйтерсең тауларның йөрәк
Тибеше бар бу суда.
Шуңа күрә тау елгасы
Горур да ул, ярсу да.

*8.09.1995*

**ЧЫК**

Зәңгәр чәчәкнең таҗында
Чык бөртеге нур сибә.
Әле зәңгәр төскә керә,
Әле саф энҗе менә.

Исем китеп карап тордым:
Бер бөртек чык туктатты.
Хәтерләтте зәңгәр күзең,
Сагышларны кузгатты.

Әйтерсең синең күзеңдә
Бер тамчы яшь бөртеге,
Зәңгәр чәчәкнең таҗына
Тамган тамчы шикелле.

Җил исте дә чык сибелде,
Җилпенеп куйды чәчәк.
Ышан, дустым, синең дә бер
Сагышларың үтәчәк,
Карашың нур сибәчәк...

**КҮКЧӘЧӘК**

Арышларның җитеп килгән чагы,
Тиздән менә урак башлана.
Арыш арасында күкчәчәкләр
Акрын гына җилдә чайкала.

Күкчәчәкләр, күктәй күкчәчәкләр,
Рәшәләргә бирә зәңгәрлек.
Зәңгәрлеккә кереп, сукмакларның
Ерагыннан килим әйләнеп.

Арыш исен, салам исен сулап,
Чикерткәләр җырын тыңлармын.
Питрау узган, тургай инде тынган,
Башак тутырыр чагы кырларның.

Чисталыкка керәм, күңелемдә
Башак шавын саклап йөрермен.
Төшләремдә, бәлки, күкчәчәкле
Шушы сукмакларны күрермен.

Бу сукмактан әле минем кебек
Сагыш басып күпләр үтәчәк...
Каршы алыр, озатып калыр сезне,
Бәхет теләп, күктәй күкчәчәк.

*10.08.1993*

**ИЮНЬ**

Син гүзәлсең, гаҗәп иркә үзең,
Рәшәләрең җылы, күгелҗем.
Ничек әле шулай баштанаяк
Шау чәчәккә, гөлгә күмелдең?

Шат елмаеп килгән сылу кыздай
Иркәлисең җанны-күңелне.
Офыкларың чиксез, зәңгәрлекләр
Синең зәңгәр күзең түгелме?

Сандугачлы таңнар, көн буена
Җанны назлап тургай җыр суза.
Арыш басулары талгын җилдә
Дулкынланып серкә очыра.

Болыннарда печән җитеп килә,
Җиләк пешкән инде алланып.
Матурлыгын, купшылыгын күреп,
Җир тора күк үзе таң калып.

*7.11.1993*

**СИХЕРЛӘНҮ**

Йөгерәләр сукмак буйлап
Кыңгырау чәчәкләре.
Зәңгәр гөлләр, күккә тиңнәр
Җанымны иркәләде.

Сихерләде зәңгәр томан –
Кыңгырауларның җаны.
Күңлемнең сезнең сыман
Челтерәп торган чагы.

*22.02.1998*

**КОЯШЛЫ ЯҢГЫР**

Тып-тып килеп уйнадылар
Җылы эре тамчылар.
Күбекләнде күлдәвекләр,
Гөрләвекләр актылар.

Юындылар ак каеннар,
Таратып толымнарын.
Кояшлы яңгыр өләште
Дым итеп бөтен назын.

Әлсерәгән болын, кырлар
Тамчы-тамчы наз эчте.
Шундый җиңел җылы парда
Иркәләнә җир өсте.

Яңгыр тынды, болыты да
Әйтерсең бетте эреп.

Җил, шаярып, тамчы койды,
Каен толымын үбеп.

*30.01.2002*

**ҖИЛӘКТӘ**

Җиләкле җирләргә чыктым,
Япмадай кызыл җиләк.
Утырып, чүгеп, үрмәләп,
Тутырып җыйдым бер чиләк.

Телем белән сыта-сыта
Татлы тәмен татыдым.
Гүя эре җиләк булып
Пешкән минем шатлыгым.

Тирә ягым җиләк кенә.
Җиләкнең өерлеге.
Җиләк исле җилләр исеп
Җанымны сөендерде.

Җиләкле үрләрдә йөрдем,
Җиләктәй пешеп үзем.
Исең китәр – үр кып-кызыл,
Сокланып туймый күзем.

*11.03.2006*

* * *

Күләгәләр эреп юкка чыкты,
Кояш төште урман артына.
Су керергә төшкән ябь-яшь таллар
Тупыллардан гүя тартына.

Әкрен генә эңгер җилме әллә
Бөдрә чугын сыйпый аларның.
Көн йокыга талды, түшәк итеп
Чәчәк белән тулы аланын.

Кем ул шулай иркә, йомшак җырлый?
Авыл өстен иңләп, моң йөзә.
Ә ул миңа төнгә багышланган
Бишек җыры булып ишетелә.

*27.06.1985*

**ТӨНГЕ ЯҢГЫР**

Бөркү, җылы төн. Еракта
Тонык күкрәү ишетелә.
Менә җил куя талпынып,
Яңгыр исен китерә.

Тузанга баткан тупыллар
Җиңелчә шаулый башлый.
Куера төн, кинәт яшен
Ярты күк йөзен аклый.

Яктырып китә тирә-як,

Зәңгәрсу төскә кереп.
Һәм кинәт көчле күкрәү!
Куясың хәтта чүгеп.

Берән-сәрән эре тамчы
Күтәрә тузан исен.
Тагын яшен, тагын күкрәү,
Көтәсең, хәзер дисең.

Җиңел шаулау йөгереп уза,
Хәбәр китергән төсле.
Һәм яңгыр тоташ стена,
Яшен телгәли күкне...

Узып китә төнге яңгыр,
Сулавы иркен, татлы.
Тупыллар, хуш ис таратып,
Коялар җиргә тамчы.

Ай чыга болыт астыннан,
Җил аңа гашыйк булып,
Эреп югала, төн шунда
Йокыга тала тынып.

*14.05.1996*

**ТЫН ТУГАЙДА**

Тын тугайда, гөлләр арасында
Җәйге йомшак җилләр искәндә,
Күңелемдә җылы хисләр туа,
Синең исмең искә төшкәндә.

Ә бу гөлләр нәкъ син үзең инде,
Кыңгыраулар – зәңгәр күзләрең.
Шуңадыр да күңлем сагышлангач,
Тын тугайда сине эзләдем.

Җырларында синең исмең кушып
Сайрый кебек тоелды тургай.
Сукмакларын гөлләр белән бизәп,
Сине көтә шулай тын тугай.

*21.03.1999*

* * *

Иртә торып кырларымда йөрим –
Арышларны иеп чык төшкән.
Тамчыларның рәшә булып өскә
Күтәрелгән тавышын ишетәм.

Урман буендагы уйсулыкта
Җил таратмый калган томанлык.
Эри бара, күренә әнә: каен
Толымнарын тарап коя чык.

Яңгырдан соң кебек урман эче,
Нурга чумган, дымлы һәм серле.
Әкиятме бу: нәни бер аланга
Кителеп төшкән салават күпере?

*15.12.1985*

**ЧӘЧӘКЛӘРГӘ**

Сезнең белән аңлашуы җиңел:
Сез аңлыйсыз мине, мин – сезне.
Сез гүзәл гөл булып шытып чыккан
Изгеләрнең җаны түгелме?

Мин сокланып, сөеп карыйм сезгә,
Ә сез миңа – якын, тиң күреп,
Иркәлисез җанны, күңелемне,
Хуш ис бөркеп, гөлләрчә көлеп.

Юк көнләшү, сатылу юк сездә,
Ә без менә – кеше дигәннәр –
Әйтсәң оят, аңга ия булып,
Аңнан качып яши биргәннәр.

Нәрсәгә аң? Аңсыз җиңелрәк.
Чумып битарафлык эчендә,
«Нигә сезгә бездәй яшәмәскә?» –
Дип әйтәсез кебек кешегә.

Юк, без сездәй яши алмыйбыздыр,
Нәфес дигән коточкыч нәрсә
Бик күпләрне, кешелектән йолкып,
Хайван рәвешендә йөдәтә.

Ә чынлыкта, эх, яшәргә иде
Бер-береңне сөеп сафлыкта.
Күзләр күзгә карасыннар иде,
Мөлдерәмә тулып шатлыкка.

Иңнәр иңгә терәк булсын иде,
Ә йөрәктә ялкын, җылылык.
Бер-береңнән шушы җылылыкны
Гомер буе тоеп торырлык.

*12.02.1998*

**РОМАШКАЛАР**

Йомшак җилләр таң нурлары белән
Ромашкалар үскән болынга
Чык таратты, ак таҗларга тезеп,
Ах, бу нинди нурлы могҗиза?

Җемелдәде болын, ак тәлгәшләр
Үз телендә көлде, җырлады.
Бормаланып киткән тап-тар сукмак
Рәшә агымында югалды.

Уйнады чык бәллүр тамчы булып,
Сибелеп, балкып акты тере нур.
Ромашкалар ак таҗларын какты,
Бар тирә-як якты һәм горур.

Монда чиста, әйтерсең җир үзе
Нурлы җанын ачып күрсәтә.
Ромашкалар, энҗе коя-коя,
Җирне данлап күкләргә дәшә.

*27.02.1998*

**БАКЧАДАГЫ ПАР ЮКӘ**

Хыялым мине еракка,
Балачагыма илтә.
Әнә мин туган нәни йорт,
Бакчадагы пар юкә.

Мин яраткан серле кичләр,
Һәмерактан килгән җыр,
Каеннарның ефәк шавы,
Йокымсыраган авыл.

Тулган ай шундый зур, якты,
Бакчаны нурга күмгән.
Җиңел калтырау тәнемдә,
Яшьле күзләрем белән.

Мин күрдем матурлык барын.
Аңладым аны, тойдым.
Сеңдердем җылы җаныма
Шул айның якты нурын.

Һәм пышылдап акрын гына
Мин нәрсәдер сөйләндем.
Гаҗәеп зур айга төбәп
Яшь каплаган күзләрем.

*27.12.1986*

**ЯҢГЫР**

Казан урамнары тоташ күбек –
Кайный-кайный ашыга гөрләвек.
Көчле яңгыр, шундый җылы яңгыр,
Кая күз сал – тулы күлдәвек.

Үземә кызык, үзем манма суда,
Көлгән булам әле бүтәннән.
Егет көлеп чыга урам аша,
Күбәләктәй парын күтәргән.

Сыңар башмак ага гөрләвектә,
Студентлар йөгерә артыннан.
Гади генә яңгыр түгелдер бу,
Ул шаярып явадыр сыман.

Ник берәүдә булсын ачулы йөз!
Бу нәрсә соң бүген, ни булган?
Казан үзе көлә безнең белән –
Балкып калган Казан, юынган.

*5.05.1997*

**ҖЫРЛЫ ЯҢГЫР**

Төн. Җылы. Яңгыр тавышы.
Түбәдә тамчы бии.

Шыбыр-шыбыр җиргә коела –
Борчак сибеләмени.

Йокы аралаш ишетелә
Кыңгырау чыңы булып.
Әйтерсең лә кемдер җырлый
Шул тавышка кушылып.

Бит чынлап ишетелә җыр
Яңгыр тавышы аша.
Бу тавыш бер югала да,
Йә тагын якынлаша.

Шундый якын, шундый таныш –
Хәтерләтә әллә ни.
Бишек җыры җырлый сыман
Тын гына миңа әни.

*7.10.1986*

**КАЕН УРМАНЫНДА**

Каен урманнарын урап йөрим.
Нинди аклык, нинди чисталык!
Ап-ак кәүсәләргә кояш сеңгән
Нур эчендә калдым таң калып.

Нур эчендә калдым, каеннарның
Җаны белән җаным сөйләште.
Бу урманнар, каен урманнары
Сихерләде минем йөрәкне.

Күтәрелеп биеклеккә карап
Зәп-зәңгәр күк күрдем, зәңгәрлек.
Әйтерсең лә шушы зәңгәрлектән
Аклык иңгән нурга әйләнеп.

Каен урманында җырлап йөрим,
Аланнарын чыгам әйләнеп.
Җиләк пешкән, чем-чем булып үскән,
Үлән сабагына бәйләнеп.

Мин үземне башка итеп тойдым,
Юынды күк җаным бу нурда.
Кәүсәләргә кулларымны куеп,
Нур агышын җыйдым учыма.

*13.12.1996*

**СЕРЛЕ ТАҢ**

Тау битләре буйлап уйсулыкка
Таң җылысы ага наз булып.
Күрәсеңме, офык читендә бер
Таң йолдызы калган онтылып.

Күр гөлләрне, ничек бизәнгәннәр,
Әй, өлгергән тажда тулган чык!
Кояш нурын җыеп, нурга чумып,

Сибә алар бәллүр яктылык.

Үзәннәрдә шундый җиңел томан
Эреп нурда нидер пышылдый.
Каеннарга сарылып тынган җилләр
Барын онытып шул серне тыңлый.

Кырлар тыныч, борма юлларына
Рәшә төшкән, серле бу таңнар.
Зәңгәрлектә кыңгыраудай чыңлап,
Таңны котлап сайрый тургайлар.

*31.03.2001*

**ИЮЛЬ**

Җиләкләрне, балландырып,
Аланнарга сиптең дә,
Болыннарны гөрләп торган
Печән өсте иттең дә,

Шаү чәчәкле юкәләргә
Бал исе бөркеп киттең.
Коры, кызу көннәр белән
Тынны, сулышны өттең.

Җилләрең тарап кырларны,
Буяды сары төскә.
Бер кешене бу вакытта
Бүлә торган чак өчкә.

Күз йомып ачкан күк кенә
Кыска бөркү төннәрне.
Ут балкышы – аҗаганнар
Җилкетә күңелләрне.

Күкрәп килгән болытларың
Күңелгә өмет сала.
Дымга сусаган кырларга
Җып-җылы яңгыр ява.

*11.11.1993*

**СИН КИТӘСЕҢ ИНДЕ**

Син китәсең, мин аңладым инде,
Туктатырга сине юк хакым.
Мин бит сине бар йөрәгем белән
Язгы гөлдәй сөеп яраттым.

Барын аңлап, йомылып бәгыремә,
Кысылып кына чыкты яшьләрем.
Бу яшерен, серле сөю иде –
Һәм без белә идек наз тәмен.

Үзең белән минем сөюемне,
Бар назыңны китәсең алып.
Җәйләремә төште мәллә кырау:
Калды кебек гомер тукталып.

Син китәсең инде, берьялгызың
Каласың, дип, язмышым дәшә.
Син яшьлегең тугаена киттең,
Минем җәем көзгә янәшә.

*6.09.2001*

**СИН ЭЗЛӘМӘ МИНЕ!**

Язгы күкрәү булып син уятма мине.
Минем хисләремә көзләр моңы иңде.
Тынды сагышларым, булган кичерешләр
Тирән сызык булып күз читендә инде.
Язгы күкрәү булып син уятма мине.

Син эзләмә мине, ләйсән яңгыр булып
Какма тәрәзәмә, тамчы, тамчы тулып.
Янып торган күзләр уйчанланды уңып,
Безнең сөю калды бары газап булып,
Син эзләмә мине ләйсән яңгыр булып.

Мин җырлаган тугай буйлап үтмә бүтән,
Ул тугайда башка җырлый инде күптән.
Язгы күкрәү булып син алдама мине,
Бар буласы булган, бар да инде үткән.
Мин җырлаган тугай буйлап үтмә бүтән.

*8.10.2001*

* * *

Томаннарга күммә мине,
Җил иссә, ул таралыр.
Оныттым дигән өметең
Хәтер булып яңарыр.

Еллар алыр әле, димә,
Бетәр, димә, сагышым!
Бетәр иде дә, җыр булып
Йөри минем тавышым.

Кил яныма, әйт үземә,
Кичер, оныт, дип, җаным.
Кичерермен, онытмамын,
Тынычлап калыр җаның.

*18.03.1991*

**НИЧЕК СИЗДЕҢ!**

Авыр көннәрем булганда,
Сагышланса күңелем –
Ничек белдең, сизә алдың?
Җылы сүз белән килдең.

Ялгыш адым ясасам бер
Һәм сизми калсам үзем –
Тагы син минем янымда,
Шелтәле олы сүзең.

Әллә инде йөрәгемнең
Тибешенә кадәр сездең –
Сыкрап типкән чагында,
Бирешмә, дустым, диден,
Тагын кулыңны бирдең.

*10.03.1986*

**БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ**

Нур булып туа көн яктысы,
Гөлләрдә яна чык тамчысы.
Күңелдә тойгылар яңара,
Саф хисләр җыр булып тарала.

Яшь йөрәк талпына, ашкына,
Туган көн юлларга чакыра.
Бар дөнья яшьлектән тора күк,
Биектә зәп-зәңгәр чиста күк.

Бу нинди ашкыну? Мин беләм,
Бәхетем ташкан чак, мин сөям.
Шуңа да башкача бу күкләр,
Искән җил, хыяллар, өметләр.

Бу тойгы сыялмас бер җанга,
Сөям, дип кычкырдым җиһанга.
Яшьлекнең иң гүзәл мизгеле –
Беренче мәхәббәт, яз гөле.

*29.03.2006*

* * *

Мин синдәйне әле очратмадым –
Шундый якын, шундый кадерле.
Бер мизгелдә син үзгәрттең кебек
Тормышымны, җанны, күңелне.

Мизгел генә, ә йөрәктә күпме
Җылы калды, якты истәлек.
Озак еллар буе хәтерләргә,
Яшәү дәверенә җитәрлек.

*5.10.1986*

**ҖЫРЫМ КАЛДЫ**

Ләйсән яңгырларда җырым калыр
Тамчы шавы булып тын гына.
Беренче кат язгы күкрәү үтсә,
Миннән сәлам булыр ул сиңа.

Шомыртларның татлы сулышыдай,
Мин үтәрмен сиңа кагылып.
Бу бит синең, синең тавышың дип,
Искә алырсың әле сагынып.

Шау чәчәкле яшел тугайдагы
Рәшә чыңы булып юлыңда
Тибрәнермен, сихри дулкын булып,
Мәхәббәтең саклап җырымда.

*13.05.2005*

**КАЙТУ**

Нинди тын бу иртә,
Шомыртлар ял итә,
Хуш исле биләүгә төренеп.
Тәлгәшләр өстендә
Энҗе чык нур сибә,
Әллә соң алыйммы үрелеп?

Ашыгып, ашкынып,
Мин кайтам талпынып.
Әле бик, бик иртә сөйгәнем.
Мин сиңа гөлләрдән
Җыярмын чык мәрҗән,
Берәмләп нур җепкә тезәрмен.

Мин инде якында,
Йөрәгем ялкында.
Син татлы йокыда, белмисең.
Төшеңдә гөлләргә,
Көтәм, дип, сөйгәнгә
Тугрылык турында сөйлисең.

*3.04.2003*

**БАР ДА ИСЕМДӘ**

Күптән инде оныткандыр, димә –
Онытмадым, бар да исемдә!
Истәлеккә кулъяулыгың саклыйм,
Чигеп язган исемең читендә...

Яшьлегебез төсе матур көннәр,
Таңнар алсулыгы бар анда.
Әй, кадерлем, синең хушбуй исен
Саклый бит ул әле һаман да.

Без үзгәрдек, бик үзгәрдек инде,
Ә кулъяулык һаман шул килеш.
Кырыйлары вак-вак күзәнәкле.
Нинди челтәр, нинди чигелеш!

Оныткандыр инде, димә берүк,
Ничек инде яшьлек онтылсын!
Без кырыктан уздык, син, кулъяулык,
Яшьлегебез төсе булырсың.

*22.03.1999*

**МИН ЮГАЛТТЫМ СИНЕ**

Мин югалттым сине, тәлгәш карлар
Синнән соңгы сәлам шикелле.
Үткәннәргә кайтма дигән сыман,
Юлларыма тирән көрт өйде.

Бар да калды, дулкын-дулкын чәчләр
Уйнап җилдә,
Тапшырдылар соңгы хисләрен.
Мин ялгыштым, сизми калдым, бәгърем,
Мин, кадерлем, әллә нишләдем.

Олы сөю, әйтер сүзләр калды,
Ах, син минем
Уйчан күзле яшьлек чәчәгем.
Адашып мин бигрәк озак йөрдем,
Ләкин сине
Сагынып һәм сөеп яшәдем.

*1.07.1982*

**СИН ЯЗМАДЫҢ МИҢА**

Хат язмадың миңа, тормыш кайчак
Кырык якка бөтереп йөртсә дә.
Авыр чакта синең җылы сүзең
Кирәклеген миңа белсәң дә.

Хат язмадың, синең өчен мин ят
Кеше булып калдым югалып.
Ниндидер бер бушлык иңде җанга,
Әрнеп калды күңел, тырналып.

Мин ялгызым калдым, истәлекләр,
Үткән көннәр, уйлар эчендә.
Эри икән күңел, рәнҗү, үпкә
Сакламадым яшереп эчемдә.

Кеше сизмәс шатлыкны да зурлап,
Бәхетле мин диеп әйталдым.
Сөю тулы үткән көннәремдә
Сине тоеп, сагынып яшәдем.

Үткәннәргә кайтсам тормышымның
Яшерен сукмагыннан хыялда,
Мин бит беләм, шул сукмакка чыгып,
Берәү көтә мине – син анда.

*10.04.1988*

**ОНЫТ, ДИДЕМ**

Онып, дидем йөрәгемә,
Хәтернең бардыр чиге.
Бер минутка китсәң икән
Уемнан ташлап мине.

Гомеремнең агышында

Күпме дулкыннар тынды.
Ә син шулар арасында
Зурысы, давыллысы.

*8.10.1988*

* * *

Күзләремә күтәрелеп карамадың,
Белә идем алар мине ят күргәнне.
Гомеремдә бүлә-бүлә санамадым
Бәхетле, дип, бәхетсез, дип, көннәремне.

Бөтенесе бер йомгак күк минем көннәр.
Ул синсез дә шул ук гомер булып кала.
Мин барын да кичерермен, ә син минсез,
Хыянәтең белән, әйдә, яшәп кара.

*24.01. 2002*

* * *

Бәгыре авыртсын, диеп
Әйттеңме бу сүзеңне?
Болытлар каплаган кебек
Булды күңел күгемне...

Минем җанымны телгәләп,
Яшенле давыл керттең;
Ярсынып, кая бәрелеп,
Ут булыр бу, дип көттең...

Барын йоттым үз эчемә,
Яндыра алмый яшен.
Хәтта күрсәтмәдем сиңа
Ялгыш кына күз яшем.

Аптырадың, кара көйдең,
Күреп тыныч чагымны.
Үзең аткан яшен өтте,
Ут күк кереп җаныңны.

*9.04.1994*

**ТАҢГА КАДӘР БЕР ҖЫР ЙӨРДЕ**

Айлы төннәр серле-серле,
Каеннарга йокы иңгән.
Йоклый алмыйм, кемдер җырлый
Үзәк өзгеч моңлы көйгә.

Мәхәббәтнең җырымы бу?
Сөюнең иң зурымы бу?
Бөдрә таллар уйчан, серле,
Көтә икән алар кемне?

Әллә җырчы югалтканмы
Сөйгән ярын, тиңдәш парын?
Тал көтәме ике парның

Табышканын, кавышканын?

Зәңгәр төннәр серле-серле,
Сихри гүзәл шушы төнне,
Парын эзләп чын йөрәктән,
Таңга кадәр бер җыр йөрде.

*20.03.1979*

**МИН КИТӘРМЕН СИННӘН**

Мин китәрмен синнән, иртәләрен
Инеш чите челтәр боз булыр.
Каеннардан, утлы сагыш булып,
Соңгы яфрак җиргә коелыр.

Мин китәрмен, берни булмагандай,
Минем өчен таллар еларлар.
Яфрак очындагы боз-тамчылар
Бер-беренә кагылып чыңларлар.

Ак бәс сарган булыр сукмакларны,
Күзге иртә булыр тын, чиста.
Моңсу тавыш белән каңгылдашып,
Киек казлар күренер офыкта.

Мин китәрмен синнән әкренләп,
Бәлки, бар да, бар да онтылыр.
Беренче нур белән сукмактагы
Минем эзләр эреп юк булыр.

Эх, тоя алсаң иде хәлләремне,
Бер мизгелгә җаныма кереп.
Миңа синсез күкләр булып күкләр
Төшәрләр күк кинәт ишелеп.

*6.04.2002*

**ШОМЫРТ БУРАННАРЫНДА**

Ашкынып, очып яныма
Килмәсеңне мин беләм.
Ләкин сөюем хакына
Мин барын да кичерәм.

Читләшсәң дә, синең назың,
Җылылыгың җанымда.
Ышан! Мин бәхетле идем
Син янымда чагында.

Мин дә синнән, таң җиледәй,
Тын гына читләшермен.
Бәлки, соңгы кат яратып
Исемең эндәшермен.

Бел, ялгышсаң, табалмассың!
Җиләсле май таңында.
Мин тын гына югалырмын
Шомырт бураннарында.

*14.10.2001*

**КУНАК КЫЗЫ**

Күршедә кунак кызы бар,
Керфеге – озын, кара.
Турыбыздан узган чакта,
Йөрәгем ярсып кала.

Әллә нишләтте бит мине
Шул озын керфекләре.
Ягымлы карашы белән
Җанымны сихерләде.

Унар кат керәм янына,
Юк кына сәбәп табып.
Ә ул мине, кергән саен,
Каршы ала елмаеп.

Эндәштем кунак кызына,
Ни булса булыр, дидем:
«Чибәркәй, керфекләреңә
Гашыйк булдым мин синең».

Кунак кызы елмайды да:
«Шаяртмыйсыңмы? – диде. –
Бер күрүдә гашыйк иттең
Син дә үзеңә мине».

*10.11.2001*

**ХЫЯЛДА**

Томаннарга әйләнеп бер
Үзәнгә төшсәң иде.
Гашыйклар йөргән сукмакны
Күренмәс итсәң иде.

Чык бөртеге булып, кунып
Калсаң иде гөлләрдә.
Энҗе сыман янар идем,
Таң сызылып килгәндә.

Рәшә булып акрын гына
Тибрәнер идем иртән,
Гашыйклар йөргән сукмактан
Үзәннәр буйлап үтсәң.

Томаннарга әйләнеп бер
Үзәнгә төшсәң иде.
Томан кочагына алып
Иркәләр идем сине.

*12.06.1991*

* * *

Күзләреңә күзем тамды минем,
Тыныч күлгә тамган тамчыдай.
Син сизмәдең аны, синең хисләр
Читтә иде, күрде аны ай.

Мин җаныңа синең сеңим дидем,
Күзләреңдә калды күзләрем.
Мин тилердем, шаштым синнән башка,
Сукыр кебек берни күрмәдем.

Син тоймадың минем сөюемне,
Син башкага гашыйк идең лә.
Минем кебек газаплана идең,
Яна, көя идең үзең дә.

Әйтмәдем сиңа, яратам, дип,
Газапларың синең күргәнгә.
Миңа түгел, башка бер йөрәккә
Мәхәббәтең барын белгәнгә.

Әйталмадым, чөнки бик бәхетле
Булуыңны синең теләдем.
Вакыт узар, онытырмын, дидем,
Тынычланыр, дидем, йөрәгем.

Еллар узды, күзләреңнең төсе
Күзләремдә калды, зәп-зәңгәр.
Ышанмагыз, сөю онытыла,
Еллар юа аны, дисәләр!

*22.08.2000*

* * *

Хыялларым тыялмадым,
Бер йомгакка җыялмадым.
Сүтелде бит, буталды бит,
Йөрәгемне ут алды бит.

Тоярсың дип уйламадым,
Сөеп карап туялмадым.
Яшьлек үтте тормышыңда –
Сиңа терәк булалмадым.

Карашыңда сагыш күрдем.
«Язмыш бездән көлде», –дидең.
Берәр канат икебездә,
Яшь тамчысы керфегеңдә.

Юлларыңда эзең калды,
Карап-карап күзем талды.
Очып булмый бер канатта,
Эзләреңә яшем тамды.

*10.02.2005*

**СӘЛАМ СЕЗГӘ**

Сәлам сиңа, кояш, сәлам, иртә.
Сәлам сезгә, искән җилләрем.
Сәлам сиңа, челтерәвек чишмә,
Сәлам, урман, таныш үрләрем.

Сәлам сиңа, яңа туган сабый,
Сәлам сиңа, бәхетле ана.
Сәлам сиңа, күпереп килгән болыт,
Тормыш дәвам итә, яңара.

Сәлам сиңа, тугайдагы колын,
Һавадагы тургай, ак каен.
Сәлам сезгә, һәрбер көнегезгә,
Гомер кичеп барган картларым.

Сәлам сезгә, изге күңеллеләр,
Уен-көлке, тормыш сөйгәннәр.
Сәлам сезгә, чын йөрәктән сәлам,
Чын дуслыкның кадерен белгәннәр.

Сәлам сезгә, мәхәббәтне данлап,
Бер-беренә тугры калганнар.
Сәлам сезгә, гади, чиста калып,
Кешелекне зурлый алганнар.

*25.03.1998*

**ЫШАНАСЫ КИЛМИ**

Бу тугайлар гел минеке булмас,
Бу чишмәләр калыр бер көнне.
Минсез җилләр исәр, туар таңнар,
Күк йолдызлы булыр һәр төнне.

Кышлар язга күчәр, җәйләр – көзгә,
Шул ук калыр үрләр, урманнар.
Лепер-лепер усак яфраклары
Минсез дә шул җырны җырларлар.

Юл читендә көчле, горур булып
Ялгыз имән шаулар күп еллар.
Эх, сокланып шушы пәһлеванга
Сәлам биреп миндәй кем узар.

Ышанасы килми, бәлки әле,
Мин бөтенләй бетмәм, калырмын.
Җәйге таңда гөлләрдә чык булып,
Кышын карлар булып явармын.

Эңгер япма булып иңәрмен мин
Җәйге җылы кичтә тын гына.
Йә бер сихри моңлы аваз булып
Әйләнермен сөю җырына.

*25.11.2005*

**БОЛЫТЛАР**

Болытлар, болытлар, кая юл алдыгыз,

Кайларда яшенләп, давыллап яудыгыз?
Әллә соң тын гына кырларга дым биреп,
Киләсез микән сез кабарып, тезелеп?

Болытлар, болытлар, сез кеше шикелле
Ярсулы, давыллы, тыныч һәм сөйкемле.
Яшеннәр атканда мәкерле куркыныч,
Кеше дә нәкъ шулай – ах, кырыс бу тормыш!

Болытлар, болытлар, чит яктаниләр бар?
Ялкынга уралган, сыкранган илләр бар.
Биектән барын да киләсез сез күреп,
Күрәсез, һәрвакыт булмыйдыр шул түзеп.

Яшенләп, күкрәп, давыллар кузгатып,
Ташытып елгалар, боз бәреп, ут атып
Үтәсез шикелле искәртеп, кисәтеп,
Җитәр, дип, бәланең асылын күрсәтеп.

Болытлар, болытлар, агыгыз тын гына,
Иминлек тамчысын сибеп җир куйнына.
Күзләрне иркәләп, аккошлар шикелле,
Очыгыз, болытлар, сез ярсу, сөйкемле.

*28.07.1999*

**ЭҢГЕР**

Узып бара менә тагы бер көн:
Тау битләрен соры нур сарган.
Су буенда таллар оеп калган,
Күләгәләр сәер озайган...

Яфрак арасына йокы төшкән,
Эңгер яткан юллар өстенә.
Ерактагы каен рәтләре дә
Кара-кучкыл тасма күк кенә.

Кемдер көлде. Чыңы ерак китеп,
Болыннарга җитеп коелды.
Яшел үрләр иркен сулап куйды,
Үләннәргә энҗе чык кунды.

Ашыкмыйча, атлы юлчы узды,
Нидер көйләп, көе сагышлы.
Чеметтереп җанны, арт урамнан
Ишетелә тальян тавышы.

*19.03.1994*

**ТЫНЛЫК**

Көн кызуы сүрелеп эңгер төште,
Хуш ис белән тулды бар һава.
Офык сүнде, урман өстендәге
Болыт кына бераз аллана.

Тынды дөнья. Әйтерсең лә бары да
Арып талган тирән йокыга.

Талгын җилдә юкәләрдән татлы
Чәчәк исе сарыла тын юлга.

Гаҗәпсенеп, күңел талгын гына
Шул тынлыкка кереп күмелә.
Нәрсә булды соң бу? Хисләр ташый,
Мөлдер-мөлдер булып түгелә...

Азга гына югаласы килә
Шул тынлыкта эреп, кушылып.
Табигатьне тыңлыйм рәхәтләнеп,
Җаным-тәнем белән онытылып.

Олы тынлык кинәт күкне биләп,
Җанга үтеп, йөрәккә керә.
Мизгел генә булып шулчак җирнең
Сулаганы ачык ишетелә.

*23.03.1995*

**МОҢЛЫ МИЗГЕЛ**

Инде кояш батып бара иде,
Эңгер ята иде үзәннәрдә.
Соңгы саргылт нурлар үрләр буйлап
Төннән качып ашыгып йөгергәндә,

Офыкларга төн билгесе булып
Кара-кучкыл юллар күренгәндә,
Өй түренә чыккан күрше-күлән
Сүз бетереп таралышкан мәлдә

Тынды авыл. Җиңел, матур итеп,
Келтерәтеп кемдер капка япты.
Шундый моңлы, гаҗәеп бер мизгел
Эңгер булып урамнарга ятты.

*26.09.2005*

**МАТУРЛЫККА БАШ ИЯРГӘ АШЫК**

Матурлыкка баш ияргә ашык.
Өлгерермен димә, гомер кыска!
Ул охшаган гөл таҗында тибрәп,
Җем-җем килеп янган энҗе чыкка.

Өлгерермен димә, сизмибез дә
Яздан җәйгә, көзгә күчкәнне.
Без дә башка идек, исеңә төшәр,
Кайчан гына әле, күптәнме?

Китәбез бит беркөн, беркем калмый.
Вакыт патша безгә, ул белә.
Күпме гомер бүлеп бирелгәнне,
Шатлык, хәсрәт тутырып кешегә.

Бу борчулы тормыш дәрьясыннан
Мизгел булып узган чагында,
Матурлыкка баш ияргә ашык,

Изге эшләр кылып калырга.

*7.06.2000*

**ҖЫРГА**

Җырсыз күңел моңсыз булыр иде,
Бушлык булыр иде бу җанда.
Кеше кеше була алмас иде,
Җыр булмаса әгәр җиһанда.

Хәтта сөю булыр иде башка,
Мәхәббәткә чиста җыр кирәк.
Күңел моңсыз-җырсыз булса әгәр,
Дәртсез тибәр иде бу йөрәк.

*27.04.1998*

**УЙНА ӘЛЕ, ГАРМУН**

Уйна әле, гармун, тарат моңың,
Җылыт әле җанны, иркәлә.
Шундый ардым, бер тын алыйм әле,
Йөрәгемә кадәр үтсәнә!

Барсын онытып бер утырыйк әле,
Калсын юк-бар уйлар, борчулар.
Синең белән икәү генә калыйк,
Югалтсыннар безне, җуйсыннар.

Эзләсеннәр әйдә моң диңгездә
Ап-ак җилкән итеп җаннарны.
Чисталыкка, яктылыкка таба
Йөзик әле онытып бар зарны.

Уйна әле, бер җырлыйсым килә,
Рәхәтләнеп, күкрәк тутырып.
Шундый ардым, бер бушаныйм әле,
Җаным белән сиңа кушылып.

*1.04.2004*

**ТӨНГЕ ГАРМУН**

Моңайганда юанырга,
Шатлык барда куанырга,
Таратырга кайгыларны,
Күңелдәге бар моң-зарны;

Җәйге төнне тояр өчен,
Тәрәз ачып куяр өчен,
Әй өздерә үзәкне дип,
Моң эченә чумар өчен;

Төнне назлап тыйнак кына,
Сандугачлар тынгач кына,
Әкрен генә барын барлап,
Төн йокысы барын аңлап;

Йоклаганга төштә кебек,

Уяуларны җилкендереп,
Уйный гармун, җырлый, көйли.
Белсәң икән, ул ни сөйли?

*15.04.1999*

**ТУГАН ЯГЫМА**

Мин яраткан уйчан таулар калды,
Серкәләнеп калды басулар.
Сабыйлыгым шунда уйнап калды,
Күпме хисләр калды, ярсулар.

Колыннарын назлап атлар калды,
Таралышып болын читендә.
Сиңа сулыш, җылы биргән яктан
Читтә яшәү бигрәк читен лә.

*11.06.1978*

**ХАЛКЫМА**

Синме соң бу «Әллүки»ле,
«Кара урман»лы халкым?
Кем шулай аңламас итте
Җаның булган җыр хакын?

Кемнәр ул җаныңа үтеп,
Алдалап бәгыреңне,
Моңсыз, төссез чор такмагын
Бу татар моңы, диде?

Чүп басты синең җаныңны,
Син кычкырдың, гөл, дидең.
«Тәфтиләү»дән, «Уел»ыңнан
Иске, дип, йөз чөердең.

Бәлки, беркөн исеңә килеп,
Гөл эзләрсең чүплектән.
Гөл тапмассың – бетәр моңың,
Гөл тамырын чүп кисәр.

*1.02.1998*

**ТЕЛЕҢ БЕТСӘ**

Телең бетсә, бетәр илең.
Ил беткәндә кем соң без?
Мескен булып бәргәләнеп,
Дөнья буйлап йөрибез.

Телең бетсә, бетәр җырың.
Җырсыз халык җансыз ул.
Телсез, моңсыз, җансыз халык –
Бер хөрмәтсез, сансыз ул.

Телең бетсә, бар да бетә.
Теле барның көне бар.
Горур җаны, туар таңы,
Гөрләп торган иле бар.

*24.12.2002*

**ТУКАЙГА**

Казан арты – Тукай сөйгән җирләр,
Шүрәлеле гаҗәп урманнар.
Һәр авылның елга-инешенең
Су анасы, торган җире бар.

Кечкенәдән Казан гүзәл булып,
Нурлы булып тартты үзенә.
«Туган тел»нең көен кем өйрәткән,
Тел ачылган көннән күңелдә.

«Тәфтиләү»не, «Әллүки»не тыңлап
Йомшамаган кемнең күңеле.
Моңлы калаң бүген сине сөеп,
Халкың зурлап җырлый түгелме?

Казан арты, синең ятим улың
Телдән телгә күчеп ятланды.
Халкы зурлап аңа, улым, диде,
Ә ул гасыр аша атлады.

*19.03.1986*

**ЯШӘ, КАЗАН!**

Гасыр катламнары күмәлмәгән
Тарих битләрендә исемең.
Казан! Казан! Ап-ак диварларың –
Нур тараткан җаның ул синең.

Бу каланың Сәйдәш моңын тойган,
Тукай килеп аңа сыенган.
Дәртле, нурлы, моңлы Казан, диеп,
Бөеклеген танып, кул куйган.

Горурланып шатлык хисе белән,
Урам, мәйданнарга күз салам.
Казан! Казан! Үсә, матурлана
Соклandыргыч гүзәл башкалам.

Халкым өчен сөекле син, изге.
Син өмете, терәге аның.
Яшә, Казан! Горур көчле кала!
Еракларга таралсын даның.

*25.08.2005*

**ӘТИЛӘР**

Әтиләр бик күпне
Күргәннәр,
Әтиләр утларга
Кергәннәр,
Сугышта үлсәләр
Үлгәннәр –
Дошманны барыбер

Җиңгәннәр.
Әтиләр –
Җирдә иң көчлеләр,
Әтиләр –
Үлемсез кешеләр.

*5.06.1973*

**БАЛАЧАКНЫ САГЫНУ**

Исәнмесез, Амар тугайлары,
Тупыллары бала чагымның.
Ишетермен төсле ысылдавын
Пинүкләрнең ата казының.

Яшел үрләр исегездәмәле,
Яланаяк чапкан малайлар?
Амар тугаенда унар кабат
Су коена иде бит алар.

Әй балачак, чынлап булдыңмы син,
Төштә генә күрдемме сине?
Татый сукмагыннан кырлар буйлап
Эзләп кайтыйм мәллә үзеңне.

Ерактагы яшел тугайларда
Уйнап калдың мәллә, кем әйтер?
«Әнә шунда, шунда йөгрә ул», – дип,
Балачакка сукмак күрсәтер.

Әй син, күңел, һаман балачактан
Чыгып бетә алмый йөрисең.
Бакча артындагы тугайларда
Нәрсә җуйдың, нәрсә эзлисең?

Әнә, күрәсеңме, болын буйлап
Аксыл чәчле малай йөгерә.
Әйтерсең ул миңа сабыйлыктан
Йөгерә-йөгерә сәлам китерә.

*13.04.1994*

**БАЛАЧАК**

Яшел чирәм, яшь бәбкәле казлар,
Шешәдә – сөт, ипи – кесәдә.
Әни биргән озын таяк кулда –
Зур ярдәмче бәбкә көткәндә.

Шук малайлар, өйле уйный кызлар,
Кибет эшли, бар да бар анда.
Яфрак акча, балчык перәннекләр
Күз алдыннан китми һаман да.

Яшь колыннар, тузганаклы болын,
Шундый матур алтын төсендә.
Кешнәп, атлар колыннарын дәшә.
Әле дә күрәм шуны төшемдә.

Бакча буйлап төшкән тап-тар сукмак,
Әни шуннан суга барачак.
Нурдай якты, җылы, матур булып
Истә калгансың син, балачак.

*3.02.2004*

* * *

Су өстендә ник бер дулкын
Кагылсын камышларга.
Бөдрә таллар черем итә,
Талганнар сагышларга.

Еракта оеп офыклар
Күгелҗем төскә кергән.
Матур хисләр ургып чыга
Шигырь булып күңелдән.

Сөялдем каенсеңлемә,
Уйларым еракларда.
Бу сукмаклар илтсен иде
Унсигездә чакларга.

Хыялым мине сагышка
Кай ара керде алып?..
Күгелҗем офыкка карап
Калдым кебек югалып.

Шул югалып торган ара
Яшьлекне урап кайттым.
Хыялда булса да, яшьлек,
Юлымда сине таптым.

*8.03.1997*

**ӘНИ ЯНЫНДА**

Син иртәгә мине уят, әнкәй,
Үзең тору белән, бик иртә.
Казларыңны куып төшәрмен мин
Җиңел томан сарган инешкә.

Һәм китәрмен чыклы сукмак буйлап,
Инеш аръягына, болынга.
Бу балага нәрсә булган, диеп,
Әллә ниләр уйлап борчылма.

Уйлама, бу барып зур калага
Ялгызлыкка, диеп, юлыккан.
Һәм эзләмә зәңгәр киңлек буйлап
Йөзеп барган ялгыз болыттан.

Нәрсә болыт? Аңа җилләр хуҗа,
Ул давыллап күкрәп ала да,
Тагын ага ерак киңлекләргә,
Көч җыярга, шаулап яварга.

Болыт түгел лә мин буйсынырга,

Бирелергә җилләр иркенә...
Тик күңелгә нидер җитми, әнкәй,
Нидер эзли җаным, җилкенә.

Нишләргә соң, минем ярсу күңлем
Әллә тапты, әллә югалтты?
Шаулы заллар үзенә тартты мине,
Җыр җылатты мине, юатты.

Сүзсез генә миңа үпкәләмә,
Әлләниләр уйлап борчылма.
Теләсәм дә, бөтен тормышымны
Сөйләп бирә алмыйм мин сиңа.
Син иртәгә мине уят, әнкәй,
Үзең тору белән, бик иртә.
Казларыңны куып төшәрмен мин
Җиңел томан сарган инешкә.

*14.11.1986*

## ӘНКӘЙГӘ

Эскертләргә сыек томан сарган,
Таллар чумган сагыш эченә.
Әнкәй бүген никтер уйга калган
Һәм тутырып яккан миченә.

Тәрәзәмне каккан җылы җилләр
Инде киткән ерак киңлеккә.
Пошкырынып инеш аръягында,
Акрын гына атлар су эчә.

Кырау булып көзләр төсе төшкән,
Төркем-төркем кошлар күченә.
Әнкәй менә никтер уйга калган,
Сөялгән дә җылы миченә.

*22.02.1979*

## ӘНИНЕ САГЫНЫП

Җилләр исә, көннәр үтә,
Бер-бер артлы үтә еллар.
Изге булып, җылы булып,
Истә калган синең куллар.

Мин бутадым еллар санын.
Сизмәгәнмен, ялгышканмын.
Биш дистәне куган чакта,
Әнкәй, җитми синең назың.

Күзләреңнең төсен эзлим,
Йомшак дәшеп уятканың.
Сагындыра су буенда
Бәбкә саклап йөргән чагың.

Елмаюлы карашларың,
Әни, диеп дәшкән чагым
Сагындыра, минем дә бит

Олыгаеп килгән чагым.

*23.12.2005*

## РӘХМӘТ СИҢА, ҖЫРЫМ

Рәхмәт сиңа, җырым, бергә булдык,
Өстә булдык, түбән төшмәдек.
Тамак диеп юк-бар чор такмагын
Үзебезгә юлдаш итмәдек.

Син канатлар куйдың бу җаныма,
Ул канатлар булды ак, чиста.
Мин беркемгә зыян китермәдем,
Дан, дәрәҗә даулап тормышта.

Кешелекне, матурлыкны данлап,
Изгелеккә дәште авазым.
Син җыр аша җирдә олы сөю,
Яшәү бөеклеген аңладым.

Рәхмәт сиңа, җырым, мин бәхетле,
Сине аңлый, тоя белүемә.
Тамырларда моң, наз булып агып,
Йөрәгемдә дәртле тибүеңә.

*20.12.2004*

* * *

Нәрсәдер эшлисе килә.
Күңел бит, нишләтәсең.
Ягымлы итеп һәркемгә
Килә бер эндәшәсем.

Аңнарлармы, көлмәсләрме?
Беркатлы, җүләр диеп.
Карый торган чормыни бу
Кешегә назлап, сөеп.

Беләм, беләм таш бәгырьләр
Заманасы икәнен.
Күрәсем килә таш ярып
Матур чәчәк үскәнен.

Син дә елмай, башкалар да
Елмайса, таш ярылыр.
Изгелек барыбер бар ул.
Күңелең нурга тулыр.

*1.03.1998*

## МИН ҖЫР БУЛЫП КАЛДЫМ

*Рөстәм Яхинга*

Казан күге ап-ак, җиңел буран
Аклык сибә, нинди чисталык.
Шул аклыкка кушылып җыр тарала,
Гаҗәпсенеп калдым тукталып.

Казан үзе тынып калган төсле
Шушы моңга, шушы тавышка.
Урамнарны айкап җырың йөри,
Җанны төреп җиңел сагышка.

Нинди ихлас, чын йөрәктән бу җыр –
Сиреньнәрнең шавы турында.
Беренче кар, шушы җиңел аклык,
Синнән сәлам төсле тоела.

Оча карлар, ә җыр һаман агыла,
Йомшап кала арган күңелләр.
Өзгәләнеп кемне сагына җырчы,
Күзләрем, дип, сине эзлиләр.

Туктап торам, шушы гүзәл мизгел
Сихерләде мине юлымда.
Мин җыр булып калдым сезгә, диеп,
Эндәштең күк үзең җырыңда.

*17.10.1996*

**БӘХЕТ ТЕЛӘРМЕН**

*Миңгол Галиевкә*

Язлар җитеп, кыр казлары кайткач,
Туган ягың сине сагына.
Алмагачлар чәчәк аткан чакта
Бер кайт әле туган ягыңа.

Бер кайт әле, печәннәре җиткәч,
Җиләкләре пешкәч болынның.
Басуларда рәшә чыңы булып,
Моңы калган синең җырыңның.

Бер кайт әле арыш кырларыңа,
Таңнарына җәйге көннәрнең.
Ә мин сиңа бар йөрәгем белән
Хәерле юл, бәхет теләрмен.

*27.11.1979*

**ӨЗЕЛГӘН КЫЛ**

*Хәйдәр Бигичевка*

Өзелде лә кылың, сынды сазың –
Сындырдылар саксыз кыланып.
Нигә хәзер мактау, данлау сүзе,
Әрнегән җан киткәч сызланып?

Ничек түзсен күңел, җырлар чакта
Иркен сулап, күкрәк тутырып?
Нечкә хисле җанны талап-тырнап...
Кара козгын торгач утырып...

Өзелә шул бәгырь, түзми йөрәк,
Ә берәүләр шуннан тәм таба.

Нинди халык соң без? Юк, кирәкми –
Талант кирәк түгел татарга.

Талантларның туры сүзе була,
Горур җаны була тәнендә.
Ул баш иеп, табан ялап йөрми
Түрә әйткән һәрбер әмергә.

Без Сәйдәшле, Яхинлы без, диеп,
Күкрәк кагып кычкырган булып...
Мәшһүрләрнең җырын җырлаучыны
Битарафлык алды куырып.

Ялганчылар, сезгә такмак кирәк,
Сезгәме соң аңлау Яхинны?
Бу җырларда сөю, яшәү, сафлык,
Чисталык һәм йөрәк ялкыны.

Бу ялкыннар куырып ала сезне,
Сез куркасыз шушы ялкыннан.
Үз ялкынын ул халкына бирде
Сәйдәшеннән алып, Яхиннан.

*24.02.1999*

**ИЗГЕ ЙӨРӘК**

*Римма Ибраһимовага*

Күпме җылы, күпме сафлык бүләк иттең.
Һәр күңелгә бу кадерле олы бүләк.
Җырдан гына, моңнан гына торадыр ул
Күкрәгеңдә тибә торган изге йөрәк.

Кимемәсен синең якты, җылы назың,
Шатлык тарат тирә-якка җырың аша.
Изге йөрәк аша чыккан ул чиста җыр
Кеше җанын изгелеккә алып кайта.

Гүзәл бул син җырларыңдай гомер буе,
Тугры дуслар тормышыңда булсын терәк!
Җырларың күк матур булсын һәрбер көнең,
Армый-талмый җырлап типсен изге йөрәк.

*4.12.1994*

**ҖЫР**

Шигырь язды шагыйрь төн йокламый,
Яше белән аны чылатты.
Йөрәгеннән алып хисен салды,
Кат-кат укып күңелен юатты.

Җыр язучы күрде бу шигырьне,
Укыганда шагыйрь китабын.
Йөрәгенә үтеп сихри сүзләр
Яшьләндерде күзләрен аның.

Күңел кылы кинәт җавап бирде,
Тибрәнде дә чыкты көй ташып.
Сүзләр җырлый һәм ул көйне инде
Булмый иде һич тә туктатып.

Җырчы отты көйне, бәгыреннән
Өзеп алып моңын өстәде.
Ул сүзләргә җылы бөркеп алды,
Ник җылады аннан, нишләде?

Таралды җыр, хискә-моңга тулып,
Күңелләргә килеп кушылды.
Кешеләргә шатлык китерер өчен
Таң чыгыдай чиста җыр туды.

*8.02.1993*

**МУЗЫКА**

Шундый йомшак, җылы сагыш булып,
Моң агыла – бу кем сагышы?
Айкап ала, канны чеметтереп,
Скрипканың уйчан тавышы.

Әнә, нидер әйтеп, вәгъдә итеп,
И биешә елгыр клавишлар!
Алар сөйли, алар ышандыра:
«Җирдә олы сөю, бәхет бар!»

Ә виолончель, үткәннәрдән килеп,
Сәлам әйтә кебек яшьлектән.
Яңагымны яндырып нәрсә узды?
Син музыка биргән яшь икән.

*30.11.1987*

**ЙОКЫСЫЗ ТӨН**

Төне буе яңгыр явып чыкты,
Тулып мичкә яңгыр суыннан,
Шыбыр, шыбыр нидер җырлады күк,
Аерырга теләп уемнан.

Җил талпынып куйган мизгелләрдә
Өзелеп-өзелеп төште алмалар.
Минем узган матур елларымны
Туп-туп килеп санады алар.

Ашыкмыйча, бөтен гомеремне
Бер төн җитте барлап чыгарга.
Кеше гомере мизгел генә шул, дип
Үпкәләдем мин ул елларга.

Төне буе яңгыр явып чыкты,
Ә мин йокламадым төн буе.
Үткәннәрдә йөрдем, киләчәккә
Бора-бора гомер юлымны.

*16.02.2002*

**ДАВЫЛЛАРГА КЕРДЕМ**

Давылларга кердем, давылларның
Көчлесенә кердем, зилзиләле.
Йөрәгемә нидер булды минем,
Җылынасым килә, бер кил әле.

Бер кил әле, бәлки, күңелемнең
Борчуларын басар сүзең булыр.
Ут сүндермәм, тәрәзәдә утым,
Соңга калып чыксаң, янып торыр.

Мин кырыктан узгач нишләдем соң?
Сагына башлыйм ерак үткәннәрне.
Минем яшьлек язым, сиздермичә,
Узганмыни инде, үткәндәме?!

Мин моңаеп калдым әллә нигә.
Нидер булды кебек йөрәгемә.
Мин аңладым: җәйләремнән узып,
Юк, керәсем килми көзләремә.

Бер кил әле миңа, ялыктырмый.
Зилзиләләр адаштырды мине.
Син алып чык, зинһар, җәйләремә,
Борчылудан арган күңлемне.

*5.10.2000*

**КИТӘ КЕШЕ**

Китә кеше, үскән нигезе кала.
Туган җире әллә ятмы аңа?
Әллә бәхет эзләп китәме ул
Таныш түгел чит-ят якларга?

Бөтенләйгә, әллә азга китә?
Һәркемнең үз юлы, язмышы.
Җиңәрме ул туган җире салган,
Яшеренеп яткан сагышны?

Озак еллар йөри кайчак кеше,
Бәгъре таштыр аның – белми дә.
Таш бәгырьле түгел, ә күңеле
Аның барыбер туган җирендә.

Ә беркөнне түзми, чыга юлга,
Рәнҗегәндәй узган елларга.
Нигезенә кайта, туфрагына
Баш ияргә, яшереп еларга.

*6.02.1986*

**ВАКЫТ**

Бар да ага, айлар, еллар ага,
Көннәр җыя, ашыга минутлар.

Барыннан да тизрәк гомер ага,
Әйтерсең лә алда яшьлек бар.

Бу агымның хуҗасы без түгел.
Ул йорт түгел, түгел мал акча,
Аны беркем сата, ала алмый,
Ул буйсынмый безгә берчакта.

Аны бикләп, терәп, тотып булмый,
Качып булмый аннан беркая.
Бөтен нәрсә аның ирке белән
Туза, сүнә, туктый, картая.

Ашыкмыйча, тулы хуҗа булып,
Ул гасырлар җыя, эралар.
Бу агымда яңа илләр туа,
Җимерелә, юкка чыгалар.

Хөкемдар юк аңа, ул ялгышмый,
Вакытында эшли барын да.
Бөтерелә, яши, кайный дөнья
Вакыт дигән шушы агымда.

*30.11.2004*

**ГОМЕР ЮЛЫНДА**

Мин күпме ялгыштым, алдандым.
Күп вакыт якыннар алдады.
Рәнҗедем, кычкырдым, ә җанда
Бернинди үч, нәфрәт калмады.

Еларлык минутлар булганда,
Арганда, талганда йөрәгем,
Елмайдым дус-ишкә, танышка,
Сиздерми ут йотар көннәрем.

Абындым, егылдым тормышның
Мәкерле юлларын үткәндә.
Йә кинәт барын да югалттым,
Бәхет ул якын дип көткәндә.

Шулай да бирешми һәр туган
Көнемә шатландым, сөендем.
Таңнарга сокландым, язларның
Ярсуы минеке күк, дидем.

Гомернең бар тәмен татыдым,
Язмышка бер үпкәм юк минем.
Җанымда якты нур сакладым.
Кагылсаң, җып-җылы күңелем.

*27.10.2004*

**КАЙТУ**

Кайтып киләм бакча артларыннан,
Балачактан таныш сукмактан.
Тупылларга иртә саргылт иңгән,

Тау битенә уйчанлык яткан.

Киртәләр дә тоя, таный кебек,
Һәр тыкрык тулы истәлек.
Туган авыл, без бит синнән читкә
Ят иткәнгә чыгып китмәдек.

Оясыннан очкан кошлармыни –
Таралыштык, язмыш таратты.
Ул үзенчә безне бәргәләде,
Ул үзенчә сөйде, яратты.

Вакыт үтә, сизелми дә икән
Гомер дигән нәрсә, уйласаң.
Әй, кырыктан узган яшьтәшләрем,
Егермедә идек без кайчан?!

Нигә ирештек без, кемнәр булдык,
Аштымы соң чынга хыяллар?
Безнең арабызда күпме икән
Адашканнар, шартлап сынганнар?

Сагынганга түзми кайтам менә,
Әрекмәннәр ерып, әремнәр.
Минем җанымдагы сагышымны
Таратырлык итеп кем сизәр?!

Кычытканнарың да гөлдәй синең,
Чишмәләрең тулы татлы су.
Бакча артларында якты тынлык –
Көзгә авышыр чак, ямансу.

– Бу сукмактан кая барасың? – дип,
Әллә инде шунда син дәштең.
– Талларымны кочып, яшьлегемнән
Китеп барышым, – дип эндәштем.

*14.06.2001*

**КАЙТТЫҢМЫ?**

Кайттыңмы?
Еллар тузаны
Кундымы иңнәреңә?
Сиздерми
Гомер сагышы
Сеңдеме күзләреңә?
Үттеме
Җилкенчәк чаклар,
Тарттымы туган җирең?
Үкенмәм,
Башка әйләнеп
Кайтмам дип киткән идең.
Йөрәкне
Булмый алдалап.
Ул тоя, сизә барын.
Кайттың бит,
Йөрәгең аша
Чакыргач туган ягың.
Ник болай

Офыклар күзләп,
Моңаеп уйга калдың?
Сизденме,
Илеңнән читтә
Гомереңнең узганын?

*17.03.2006*

**КЕШЕ ГОМЕРЕ**

Кеше гомере,
Нәни чишмә кебек,
Чыңлап ага башлый.
Ул юлында
Күпме борылышлар,
Шарламалар ясый.

Аннан чишмә
Җитез инеш була,
Шаян үсмер кебек.
Үзәннәрдән,
Таллар арасыннан
Йөгереп уза көлеп.

Уйчанлана,
Тулылана инеш,
Ярларыннан ташый.
Елга булып
Ага кеше гомере,
Дулкынлана, ярсый.

Ага елга
Көчле, гүзәл булып
Чал диңгезгә таба.
Ә каядыр
Яңа көмеш тавыш,
Үзенә юл яра,
Яңа гомер ага.

*2.07.1985*

**ГОМЕР АТЫ**

Томырылдың да чаптың, әй син, гомер,
Нигә әле болай ашыктың?
Йөгәнләргә теләгән лә идем,
Өлгералмый калдым, ялгыштым.

Уйнап кына, шулай бер шаярып,
Юртып кына килим дигән идем,
Кем уйлаган, тормыш дигән юлдан
Җилдәй җитез чабасыңны синең.

Туктамакчы булам, туктатмакчы,
Кайда синең яшел үзәнең?
Язларымны үтеп, җәйдән барам,
Ерак түгел, түгел көзләрем.

Томырылдың да чаптың, алдадың ла,

Яшьлек белән минем йөрәгем.
Ә ул миңа узмас кебек иде,
Уза калса, тиздер димәдем.

Гомер атым, сикәлтәләр аша
Ашыгасың, кая чабасың?
Кайда соң ул синең яшел үзән?
Килә туктап бер хәл аласым.

*6.04.1997*

**ЯКТЫЛЫККА ҮРЛӘ!**

Тормыш тормыш инде –
Үзенекен итә,
Сорамыйча бездән бернәрсә.
Көтмәгәндә шатлык булып керә,
Нишли алыр идек, кермәсә?

Нәрсә әйтер идек?
Килеп кайгы булып,
Бусагага ятса аркылы.
Йә кычкырып көлсә, син – минеке, диеп,
Син ялгыштың, диеп, бу юлы.

Хәйлә, мәкер тулы
Юлларына дәшсә,
Сынамакчы булып үзеңне.
Дусларыңнан айрып,
Адаштырып йөртә,
Ялгыз башы, диеп, түзәрме?

Яктылыкка үрлә!
Ышан, караңгылык
Читендә бар барыбер яктылык.
Өмет нуры сибеп, ышандырып,
Дәшә безне алга чакырып.

*12.04.1996*

**РӘХМӘТ СИҢА, ЯЗМЫШ**

Рәхмәт сиңа, язмыш, бу дөньяга
Әйдә килсен, тусын, диюеңә;
Яшәр өчен купшы сарай түгел,
Гап-гади өй салып бирүеңә.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, туган өем,
Җыр-моң белән тулы булган өчен;
Күңелемә шушы моңнар аша
Матурлыкның ачтың кодрәт-көчен.

Рәхмәт сиңа, балачагым күген
Ачык зәңгәр, матур иткәнеңә,
Каеннарның йомшак ефәк шавын
Шигырь итеп җанга керткәнеңә.

Рәхмәт сиңа, язмыш, егылганда,
Аягыма бастырганга кабат;

Гаделсезлек барда әйтә алганга,
Дөрес түгел, диеп, туры карап.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, бу җанымны
Таш бәгырьле, салкын итмәгәнгә;
Дусларыма ярдәм кирәк чакта,
Читкә карап узып китмәгәнгә.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт. Йөрәгемдә
Үткәннәрдән кала якты сагыш.
Юлларымда юлдашым бул минем,
Ярдәмеңнән ташламачы, язмыш!..

*2.04.1995*

**МИКУЛАЙ ДӘДӘЙ**

Син һаман да шулай, Микулай дәдәй,
Су буйларын урап йөрисеңме?
Нидер көйләп, уйчан караш белән,
Яшьлегеңне әллә эзлисеңме?

Култыгыңда әрекмәннәр булыр –
Куяннарга болар, беләм инде.
Мин яратам синең инеш буйлап
Тыныч кына кайтып килүеңне.

Йөзең якты, димәк, бары да имин,
Әле барлыйсың бар үрдәкләрне.
Елга буендагы таллыкларда
Җиләсрәк бераз, тыныч, ямьле...

Микулай дәдәй килә тыкрык буйлап.
Авылымның анда бөтен яме.
Алты дистә гомер кай арада
Аккан сулар кебек үткән әле?

Ә күңеле яшь чактагы кебек.
Сынаса да тормыш сындырмаган.
Олы җанлы олпат кеше килә,
Микулай дәдәй килә олы урамнан.

*21.03.1995*

**БӨРМӘНЧЕК**

Әй бөрмәнчек, бөрмәнчек,
Бул син безгә бөркәнчек;
Бәлаләрдән яклаучы,
Чир-зәхмәттән саклаучы;
Кайгыларны боручы,
Бәхет биреп торучы;
Кагыл син мал-туарга,
Зурларга, балаларга;
Шатлык булып кер өйгә,
Тынычлык бир күңелгә.
Кечкенәләр зур үссен,
Әби-бабай нык йөрсен;
Булсын бәхетле туйлар,

Тусын кызлар һәм уллар.
Әй бөрмәнчек, бөрмәнчек,
Бул син изге бөркәнчек.

*7.10.1999*

**УНҖИДЕДӘ ИДЕК**

Унҗидедә идек, ялкын идек,
Матур идек, гөлләр шикелле.
Безнең өчен бер могҗиза иде
Яшьлек тулы елның һәр көне.

Унҗидедә идек, яңа янган
Йолдыз кебек иде йөрәкләр.
Хыялландык, якты иде уйлар.
Матур, чиста иде теләкләр.

Унҗидедә идек, керсез идек,
Җанда сөю яңа уянган.
Без йолдызлар тота ала идек,
Без өстәрәк идек хыялдан.

Унҗидедә идек, җүләр идек,
Бәхетлеләр идек, шаяннар.
Чын дуслыкның кадерен белә идек,
Без дусларга тугры калганнар.

Унҗидедә идек, әкиятләрнең
Иң матуры иде ул көннәр.
Еллар үтә, сүндермичә саклый
Яшьлек утын безнең күңелләр.

*11.05.1999*

**ЭЛЕКТРИЧКАДА**

Гөрләп бара вагон тулы кеше.
Басып тора карчык, бөрешеп.
Кырыенда ике яшь пар утыра,
Җәелешеп, кыргый көлешеп.
Әйтерсең лә вакыт туктап калган,
Шушы гамьсезлеккә таң калып.
Эшләпәмне изәсең бит, хайван,
Дип акыра ямьсез бер тавыш.
Моңсу булып китте кинәт җанга,
Гаепле күк сиздем үземне.
Бу нәрсә бу?
Кинәт вагон эче
Тальян тавышына күмелде.
Әллә җылый, әллә җырлый тальян.
Өнсез калды вагон, тын калды:
Саташудан айнып киткән сыман,
Нәрсә бу, дип, ни булды тагы?
Бу – моң гына,
Шулай кеше җаны
Тальян аша чыга, моң булып.
Әйтә төсле ул җан: бу тормышта
Мин ялгызым калдым, онтылып.

Тиздән минем туктальшым җитә,
Нәрсә эшли алам мин сиңа –
Вагоннарда язмыш куып йөрткән
Ап-ак чәчле сукыр җырчыга?
Тальян чыңлый, ә бер читтә тора,
Читенсенеп, иске эшләпә.
Туктальшым.
Мин ашыгып чыгам,
Эшләпәгә салып биш тәңкә.

*7.07.1992*

**БӘХЕТ ТУРЫНДА**

Ул бәхетле, бай, акчалы, диләр,
Акчадамы бәхет? Юксана!
Кемдер күпкә байдан бәхетлерәк,
Каравылчы булып торса да.

Әнә берәү, бөтен йөзен тутырып,
Балкып көлә, нинди бәхетле.
Берни белән үлчәп булмый аны,
Биктә тотып булмый бәхетне.

Ул иркәле, мизгел генә булып
Килә, китә ала бер көндә.
Кайчак бәхет хисен тою өчен
Елмаю да җитә кешегә.

Ә шулай да шушы татлы мизгел
Кагылып үтсен иде күбрәк.
Мин бәхетсез түгел әле, диеп
Типсен иде безнең бу йөрәк.

*15.10.2001*

**САЙЛАУДА**

Әй сөйлиләр «халык», «милләт» диеп,
Тау-тау булып вәгъдә бирелә бит.
Коймаларда күпме чит-ят йөзләр,
Чакыралар тавыш бирергә дип.

Берәүләре күпер вәгъдә итсә,
Икенчесе сала юллар безгә.
Барысы да кеше өчен «тырыша»,
Әзер булып җанын да бирергә.

Андерсенның әкиятләре кебек,
Бу вәгъдәләр урап ала бар җанны.
Әгәр мөмкин булса, вәгъдә өчен
Төшерерләр иде тартып Айны.

Сайлаудан соң бары да кала тынып
Вакытлыча киләсенә хәтле.
Әкият бетә, безнең өчен кала
Мескен булып яшәү мәшәкате.

*26.05.1995*

**КИЧЕРЕРГӘ КИРӘК**

Кичерергә кирәк, кайчагында
Бәгырь телеп авыр әйтсәләр дә.
Эндәшмичә калу алтын кайчак,
Түбәнлектән өстен булыйк әйдә!..

Кичерергә көч табарга кирәк,
Изгелекләр җирдә кылу өчен.
Әйтелә шул, әйткән чакта авыр,
Үзеңне дә кичерсеннәр өчен.

*29.12.1985*

**ДУСТЫМА**

Тормыш – диңгез, ә син – нәни көймә,
Чайкалучы шушы диңгездә.
Күңелең синең ап-ак киндер җилкән,
Җилкәннәрне җилләр киерә.

Җил көймәне диңгезләргә куа,
Җилләр – язмыш – шуны онытма.
Җилкәннәрне керләнүдән сакла,
Давылларга омтыл, курыкма!

Тик ялгышма, җирдә берьялгызың
Давылларга керү куркыныч.
Ак җилкәнле дусны юлдаш ит син,
Юлдашсызны җиңә ул тормыш.

*2.03.1979*

**БЕР ТАНЫШКА**

Исем китте: тәкәббер төс алып
Исәнләшми үттең тагын да.
«Бу мескенгә нәрсә булды икән?» –
Дигән сорау туды җанымда.

Сәлам бирү акча җуюмыни,
Зыян мәллә аннан җаныңа?
Ә уйласаң, сәбәбе зур икән:
Алгансың ла икән машина!

Уйлавынча, хәзер кеше булган,
Сайлап кирәк сәлам бирергә.
Телем калмас, «саумы» диеп үттем
Шул чүбек баш, шып-шыр тилегә.

*8.03.1997*

**ЮХА ЕЛАН**

Кит, син яндырма мине үтәли,
Карашыңда утлы күлү генә.
Бит болай да минем бу йөрәгем
Күмер генә инде, күмер генә.

Мин аңладым: синең бу гүзәллек

Тәкәбберлек белән сугарылган.
Чиста хисне, керсез мәхәббәтне
Пычрата, таптап уза торган.

Бу гүзәллек тозак, капкын кебек,
Үз корбанын көтеп ала белә.
Татлы теле белән алдап, баллап,
Йөрәгеңнең уртасына керә.

Чага аннан, синең мескен булып
Каршысында тез чүккәнне көтә.
Акыл җуеп җебеп төшсәң әгәр,
Сине чүпрәк ташыр колы итә.

Кит, эчтән бозык синең гүзәллек
Аны тоя, сизә белү кирәк.
Тозагына кабып, агуланып,
Кол булмасын өчен сөйгән йөрәк.

*12.11.2003*

* * *

Авызың тулы пычрак сүз,
Җыйганың – шакшы хәбәр.
Үзең дә син тынчып беткән
Зур чүп өеме кадәр.

*2.11.2004.*

* * *

Мин беләм, безне беткә дә
Санамаган затлар бар.
Безнең канны, җанны суырып
Бүртенгән бетләр алар.

*4.11.2005*

**ТАШ ЙӨРӘК**

Җаның бармы синең, әй мескенем,
Ни өчен син шундый битараф?
Көлүең дә бит кешечә түгел,
Күзләреңдә ят һәм чит караш.

Ул караштa күпме салкынлык бар,
Тәкәбберлек каткан йөзеңә.
Бу кадәрле пычрак, шакшы сүзләр
Каян килә синең телеңә?

Әйтерсең лә дөнья хуҗасы син,
Карап торам: исең китәрлек.
Затлы кием, чит ил машинасы,
Яшең дә яшь, акчаң җитәрлек.

Бу көнләшеп тора инде, димә,
Әрнеп торам, эчтән сызланып.
Егермедә гарипләнеп беткән

Йөрәгеңне күреп, кызганып.

Кем соң каршы булсын, әйдә, барда
Затлы кием, акча, машинаң.
Белмисең бит, шуңа алмаш итеп
Йөрәгеңә шайтан таш куйган.

Күренеп тора: синең таш җаныңда
Юк кызгану хисе, изгелек.
Синең кебек таш бәгырьләр бүген
Дөнья булә, күкрәк киереп.

*25.03.1994*

**КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫП КАРА**

Авырлыклар күрә-күрә,
Газапларга түзә-түзә,
Кеше булыйм дия-дия,
Кемнәр ничек тырышмаган.

Кемдер эшләп, кемдер талап,
Намус сатып, ялап табан,
Бу дөньяда үз урынын,
Юктыр дим мин, табалмаган.

Шушы юлда кемнәр генә
Абынмаган, ялгышмаган.
Бик күпләрдә кешелектән
Тик күләгә бары калган.

Һәрберебез чиста һәм саф
Туабыз ла бу дөньяга.
Ә син менә яши-яши
Кеше булып калып кара!

*20.02.1998*

**БЕЗ ЮГАЛДЫК**

Без югалдык.
Еллар күмде безне.
Мәшәкатьләр күмде,
Борчулар.
Ялган белән
Кадерсезлек күмде,
Без нишләдек дигән
Сүз, уйлар.
Безнең җанны
Сытып, таптап китте
Кеше сөйми торган
Чор, заман.
Юк, чор түгел!
Кеше бер-берсенә
Бүре сыман бүген,
Шул яман.

*17.01.2006*

* * *

Болыннарда моңым калды,
Ишетсәң, җый җаныңа.
Ак канат булсын иде ул
Синең хыялларыңа.

Сукмакларда сүзем калды,
Тылсымлы шигъри телдә.
Ишетсәң, өйрән син аны!
Шигырь – нур ул күңелдә.

*18.04.1999*

**ХЫЯЛЫЙ**

Син тирәннән уйламыйсың, дисең,
Бәхәсләшмим, бәлки, шулайдыр.
Мин үземнән узып башка берәү,
Үземә ят кеше булалмыйм.

Хыялый, дип карыйсың син миңа,
Яшерен көлү кайчак йөзеңдә.
Тормыш итү авыр булыр сиңа,
Авыр алма, дисең, күңлеңә.

Нәрсә диим сиңа? Үпкәләмим,
Жәллимен тик бары мин сине.
Үзе өчен генә яши торган
Ике йөзле төссез кешене.

Синме соң, әйт, минем уйларымның
Тирәнлеген аңлый белерлек?
Минем хисләремә, уй-хыялга,
Яшәвемә бәя бирерлек?

Акча, байлык җыеп, хисләреңнән
Тимер ишек белән бикләнеп,
Чүпрәк хыял белән яшисең син,
Һәрбер шакылдауга шикләнеп.

Шул да булдымыни олы бәхет?
Синең тормыш күпкә газаплы.
Мин хыялый, ләкин хыялларым
Чиста минем, матур һәм якты.

*12.09.1988*

**ФОТОСУРӘТ**

Фотосурәт ята өстәлемдә –
Унсигез яшь. Нинди чак булган!
Минме соң бу? Күрче, күзләр шаян!
Яшьлек нуры белән балкыган.

Яз гөледәй яшьлек төсе калган,
Иреннәрдә калган елмаю.
Җилләр ачкан күлмәк изүләрен –
Көч, дәрт ташый. Һич юк моңаю.

Әйтерсең лә очып китәрмен күк,
Зәңгәр киңлекләргә, талпынып.
Малайлыктан, яшьлек, сиңа килдек,
Бөркет сыман ашыгып, ашкынып.

Өстәлемдә ята фотосурәт –
Яшьлегемнең матур мизгеле.
Елмаюлы җылы караш белән
Сәламлидер кебек гел мине.

*19.01.2001*

* * *

Елама, зинһар! Аңламый,
Жәлләп, мескен, диярләр.
Ә мин синнән горурларны
Әле күралмадым.

Ыңгырашма, кемгә кирәк,
Түз, тешләрең кысып.
Зәгыйфь, диеп типкәләрләр –
Чоры шундый аның.

*22.02.1988*

**КОРЫ КУАНЫЧ**

Ул – алтын, диделәр, куандылар,
Милләт бәхетенә туган, диеп.
Мактадылар, аннан мактандылар,
Илне зурлар ул, дип, күккә чөеп.

Уңды алтын, күгәреп үк чыкты,
Сары калай булды милләт даны.
Бер уйласаң, күпме вак-төяк
Алдап ята бүген без татарны.

*4.02.2005*

**АК ФӘРЕШТӘ**

Ап-ак халат киеп, яшь кыз сыман,
Шундый җиңел киләсең атлап.
Әй, хирург ханым, мөмкин булса,
Алыр идем сине кочаклап.

Учларыма алып кулларыңны
Үбәр идем, изге бу куллар.
Бу кулларның кеше йөрәгенә
Сихәт бирә торган көче бар.

Ашыгасың, авыру көтә сине,
Фәрештәләр булсын булышчы.
Кулларыңа үтә бер сизгерлек,
Җаныңа нур өреп торучы.

Шушы нурны гомер җебе итеп
Тоташтырырсың син йөрәккә.
Шуңадыр да сөеп сиңа һәркем,
Ах, фәрештә, диеп эндәшә.

*28.01.1998*

**ҮЗЕМ ТУРЫНДА**

Сагышым да үземнеке,
Шатлыгым да, бар да бар.
Кайгым булса, бар өметем,
Өмет барда – хыяллар.

Бер сөенсәм, бер моңаям,
Бикләнеп үз эчемә.
Миңа да сыеналар бит,
Мин дә сыенам кешегә.

Бар ачулы һәм ярсулы
Нәфрәт тулы көннәрем.
Ләкин җанда ачу, мәкер
Саклап йөртә белмәдем.

Кечедән рече булалдым,
Горур булдым кирәктә.
Дус-танышка елмаюлы
Сәламем бар йөрәктә.

*6.03.1997*

* * *

Арды канат.
Яраланган канат
Хәле бетеп төште салынып.
Ыңгырашып,
Ярдәм көтеп кеше
Ауды, канатына абынып.

Ләкин аны
Беркем жәлләмәде,
Таптап узды канлы канатны.
Аннан кинәт
Ачу тулган йөрәк
Читкә ыргылырлык көч тапты.

Читтән карап
Кеше дигән затка,
Онытып үзе кеше икәнен,
Рәнҗеп, сыкрап,
Бөтен кешелекне
Ул каргады, җыеп юк хәлен.

Бу тапталган,
Кимсетелгән җанда
Бары нәфрәт – сөю юк монда.
Әй, кешелек,
Үз-үзеңне таптап,
Син атлыйсың кебек упкынга.

*15.12.1997*

* * *

Ап-ак кәгазь, тәлгәш-тәлгәш булып
Бу битләргә минем хисләр төшкән.
Сез табарсыз мине һәрбер сүздән,
Шигырь булып хисләр аккан төштән.

Бөтен гомер шигъри тезмә булып
Күчкән монда, той һәм укы гына!
Алып китәм сезне үзем белән,
Шул тезмәдән якты хыялыма.

Юлларымда җырланасы җырлар
Рәшә кебек тибрәп ята сыман.
Йә мин үтәм ак томандай чиста,
Дулкынланган моңнар арасыннан.

Шигъри юлда җырланасы җырлар,
Әйтеләсе сүзләр бар да монда.
Яшьле күзләр, бар йокысыз төннәр,
Чынга ашмаган сөю сукмагымда.

Ап-ак кәгазь җаннан ташып чыккан
Күпме җылылыкны сыйдырган.
Мин сүзләрдән пейзаж ясый беләм,
Шомырт шавын ишетәм шигырьдән.

Җилпенәм дә канатларым белән,
Берсе шигырь, берсе җыр аның.
Гаделлеккә сусап, матурлыкны
Тойганнарга каршы очамын.

*20.11.2005*

**БЕЗНЕҢ ИЛ**

Безнең ил – сандугач сайрар җир...

*Керәшен татарлары җыры*

Илеңнән еракта чит җирдә
Бик авыр, дусларым, күңелгә.
Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.
Мин дә бит, мин дә бит шул җирнең
Былбылы, сөекле баласы.

Таңнарын сагындым, ай, җилен,
Агышын, шаулавын Иделнең.
Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.
Мин дә бит, мин дә бит шул җирнең
Былбылы, сөекле баласы.

Түзмәдем: ашкындым, талпындым –
Моңнары чакырды халкымның.
Безнең ил – сандугач сайрар җир,
Безнең ил – гөл-чәчәк арасы.
Мин дә бит, мин дә бит шул җирнең
Былбылы, сөекле баласы.

*3.07.1985*

**КОРБАШ АВЫЛЫ КӨЕНӘ**

Без урамнан барган чакта,
Без урамнан барган чакта,
Карагыз ла, ай-гай-һай.
Без җырлашып барабыз ла,
Без җырлашып барабыз шул,
Тыңлагыз ла, ай-гай-һай.

Яңгырасын җырларыбыз,
Яңгырасын җырларыбыз,
Еракка ла, ай-гай-һай.
Бу дөньяга безләр килгән,
Бу дөньяга безләр килгән
Кунакка ла, ай-гай-һай.

Әле бер көн сагынырсыз,
Әле бер көн сагынырсыз,
Бу көннәрне, ай-гай-һай.
Ул чакларда без йөрмәбез,
Ул чакларда без йөрмәбез
Җырлашып ла, ай-гай, һай.

*16.12.1994*

**ТОРНАЛАР ҮТТЕЛӘР**

Торналар, сез кайдан, еракмы юлыгыз?
Бу нинди моң сезнең агымда?
Туктадым, түзмәдем, эндәште йөрәгем:
– Таныш моң бу, – диеп, – җаныңа.

Кушымта:
Сезнең бу тавышта үпкәме язмышка,
Әллә соң юлларның газабы?
Давыллар аерган, канатын каерган
Парларның юксыну авазы?

Сез әнә биектә, тезелеп бер җепкә,
Чит якка, ят җиргә юл алган.
Булсам да илемдә, көнләшеп мин сездән,
Күз алмыйм сез очар юллардан.

Кушымта.
Минем дә бар иде, канатым пар иде,
Мин аны тиң күреп яраттым.
Тик язмыш аерып, алды шул каерып,
Иңемнән шул ап-ак канатым.

Кушымта.

Торналар үттеләр, юатып киттеләр
Әрнегән, сызланган җанымны.
Тик калды моң гына, тибрәнеп тын гына
Дәште күк, тап, диеп, парыңны...

Кушымта.

*23.03.1996*

**ШҮРӘЛЕ**

Яшим калын урманда,
Өй иттем дә имәнне.
Мин мөгезле һәм йонлач,
Исемем минем Шүрәле.

Кушымта:

Минем исемем Шүрәле,
Туган як – Кырлай.
Бездәгедәй гүзәл як
Башка юк бугай.

Миңа тарак кирәкми,
Кисмимен тырнакларны.
Кытыкларга яратам
Кызларны, малайларны.

Мин һаман да ялгызым,
Дуслар табарга телим.
Кил әле, кил яныма,
Бер кытыклап көлдерим.

*22.01.1992*

**КӨМЕШ ЯҢГЫР**

Җем-җем килеп су өстендә
Якты нур уйный.
Ай талларның бөдрәләрен
Көмешкә буйый.

Үзәннәрдә дулкын-дулкын
Тибрәнә томан.
Тал толымына уранып
Җил йоклый сыман.

Яфрак очында җемелдәп
Тамчылар яна.
Чык яңгыры, көмеш яңгыр
Тып та тып тама.

Бөдрәләргә кагылып алсаң,
Көй чыгар сыман.
Гаҗәеп чың таралыр күк
Һәрбер тамчыдан.

*14.03.1993*

**ӘЙ ТАУ БУЕ**

Әй тау буе, тау буе ла,
Тау буенда тал куе,
Тал буенда тал куе;
Тал төбендә салкын чишмә
Челтер-челтер көн буе,
Челтер-челтер көн буе.

Әй тау буе, тау буе ла,
Сандугачлары моңлы,
Сандугачлары моңлы;

Үзем җырлыйм, үзем тыңлыйм
Йөрәктән чыккан моңны,
Йөрәктән чыккан моңны.

Әй тау буе, тау буе ла,
Бик сагындым бу юлы,
Бик сагындым бу юлы;
Туганнарым, сезне күргәч,
Күңелкәйләрем булды,
Күңелкәйләрем булды.

*15.12.1994*

**КИЧЕР МИНЕ**

Борчылырга мәҗбүр иткән булсам,
Сагышланган булсаң мин юкта,
Кичер мине. Бәхет тулы көннәр,
Шатлык булган чакны онытма!

Көнләшергә мәҗбүр иткән булсам,
Йә рәнҗеткән булсам гел юкка,
Кичер мине. Безнең йөрәкләрнең
Бергә типкән чагын онытма!

Йөрәгеңдә сызлау, сыкрау булып,
Мин булмасам шундый минутта,
Кичер мине. Ләкин сине сөеп
Яшәүче мин барын онытма!

*24.06.1985*

**ЭЗЛӘМӘ, ЮК ИНДЕ**

Эзләмә, юк инде
Без йөргән сукмаклар.
Күптәннән сүнгәннәр
Без яккан учаклар.

Көлен дә җил исеп
Тараткан, туздырган.
Безнең дә чәчләргә
Көл сыман төс кунган.

Ә күңел шундый яшь –
Бирешми бернигә.
Әйтерсең сызыклар
Юк ирен читендә.

Әйтерсең күзләргә
Моң-сагыш иңмәгән,
Без яккан учакның
Ялкыны сүнмәгән.

Бары тик күчкән ул
Ут булып йөрәккә.
Шул безнең күңелне
Яшь итә, дөрләтә.

*10.06.2000*

**КЫЙГАЧ КАШЫМ***

Тәрәз пәрдәң күтәр, җаныем,
Күримче йөзләреңне, йөзләреңне.
Алсу алма кебек үзең,
Алалмыйм күзләремне, күзләремне.

Кушымта:

Карлыгачым, кыйгач кашым, карлыгачым, кыйгач
кашым,
Яндырдың йөрәгемне.
Төн йокыларымны алдың, төн йокыларымны алдың,
Өзәсең үзәгемне шул,
Өзәсең үзәгемне, ай, өзәсең үзәгемне.

Башкаеңда ак калфагың,
Көмеш тәңкә тезгәнсең, ай, тезгәнсең.
Гөл димимен, син гөлдән дә
Матурырак үскәнсең, ай, үскәнсең.

Кушымта.

Сөюеңне сизәм бит мин,
Күрсәтер идең йөзең шул, ай, йөзең.
Күрсәтер идең дә йөзең,
Сөям дип әйтә күзең шул, ай, күзең.

Кушымта.

**СИН ИКӘНСЕҢ**

Син икәнсең якты көне,
Җылы җилләре язның.
Син икәнсең ул саекмый
Торган коесы назның.

Син икәнсең тормышымның
Кояшы, йолдызлары.
Син икәнсең ул гаҗәп гөл,
Гөлнең сулмый торганы.

Син икән ул мине аңлап,
Бәлаләрдән йолучы.
Син икәнсең йөрәгемә
Дәрт, хис өстәп торучы.

Син икән ул тыйнак кына
Гади матурлык белән
Якты нурым, матур җырым
Булып җаныма иңгән.

*9.02.1998*

**АЙЛЫ ТӨНДӘ***

Айлы төндә керфегеңдә
Җемелди көмеш нурлар.
Көлүең дә сихри синең,
Кулымда синең куллар.

Кушымта:

Без икебез бер бөтен без,
Ай бездән көнли сыман.
Миңа рәхәт синең җылы,
Ягымлы карашыңнан.

Айлы төндә икәү бергә,
Бездән кем бәхетлерәк,
Бер-береңне аңлап, сөеп
Типкәндә ике йөрәк?

Кушымта:

Без икебез бер бөтен без,
Ай бездән көнли сыман.
Миңа рәхәт синең җылы,
Ягымлы карашыңнан.

**МОҢАЙМА**

Моңайма, моңайма, торналар
Күзләрен гел шулай очалар.
Моңайма, сагышлы бу аваз –
Ул безнең яшьлектән кайтаваз.
Моңайма!

Моңайма, моңайма, сагышка
Алданып, бирешмә язмышка.
Моңайма, тормышта бар да бар –
Сагыш бар, хәсрәт бар, шатлык бар.
Моңайма!

Моңайма, моңайма, ышан, көт,
Җаныңда сүндерми йөрт өмет.
Моңайма, яшибез бит әле,
Хәтерлә, кызганма үткәнне.
Моңайма!

*1.09.1999*

**ЭЧТӘЛЕК**

Шагыйрь җырчы. *Равил Фәйзуллин* ............

И җыр гынам, җырым... ..................

Кояшка гимн
Җәй ахыры ..........................
Миләшләр ..........................
Алма коелган төндә .....................
«Бөтерелә су өстендә сары яфрак...» ...........
Күләгәләр дә төсле! .....................
Көзге моң ..........................
Көзге бакча .........................
«Көзге иртә, салкынча җил...» ..............
Көзге яңгыр .........................
Казлар китә .........................
Бәгырь ............................
«Каеннарга җете булып...» ................
Сукмак ............................
Әбиләр чуагы ........................
Хуш инде, көз ........................
Ноябрь ............................

Кара карга .........................
Миләш ...........................
Кышкы төндә ........................
Авылда чакта .......................
Күктә ай йөзә .......................
Тәрәзәләр артында кыш .................
Агымсулар .........................
Март ............................
«Еракта, офыклар читендә...» ..............
Яз ..............................
Язгы бакчада ........................
Бөреләрен ача сиреньнәр ................
Тәрәз төбем сирень ....................
«Төн...» ...........................
Тургайлар кайттылар ...................
«Узды яңгыр, җылы, шифа тулы...» ............
Язгы көндә .........................
Гөрләвекләр эзлим ....................
Көнләшү ..........................
«Кечке эңгер, бакчаларга иңеп...» ............
Дулкыннар .........................
Болыт ............................
Челләдә ...........................
«Дулкын-дулкын җылы агым...» ..............
«Әле бу йомшак үрләргә...» ................
Язгы талпыну... .......................
«Ардың мәллә, сеңлем? Утыр әйдә...» .........
Тугайларым .........................
Күңелем якын күрә ....................
Кояшка гимн ........................
Тау елгасы .........................
Чык .............................
Күкчәчәк ..........................
Июнь ............................
Сихерләнү .........................
Кояшлы яңгыр .......................
Җиләктә ..........................
«Күләгәләр эреп юкка чыкты...» .............
Төнге яңгыр .........................
Тын тугайда .........................
«Иртә торып кырларымда йөрим...» ...........
Чәчәкләргә ........................
Ромашкалар ........................
Бакчадагы пар юкә ....................
Яңгыр ............................
Җырлы яңгыр ........................
Каен урманында .....................
Серле таң .........................
Июль ............................

Син китәсең инде
Син китәсең инде .....................
Син эзләмә мине! .....................
«Томаннарга күммә мине...» ...............
Ничек сиздең! .......................
Беренче мәхәббәт .....................
«Мин синдәйне әле очратмадым...» ...........
Җырым калды .......................
Кайту ............................
Бар да исемдә .......................
Мин югалттым сине ....................
Син язмадың миңа ....................
Оныт, дидем ........................
«Күзләремә күтәрелеп карамадың...» ..........
«Бәгыре авыртсын, диеп...» ................
Таңга кадәр бер җыр йөрде ...............

Мин китәрмен синнән ...................
Шомырт бураннарында .................
Кунак кызы .........................
Хыялда ...........................
«Күзләреңә күзем тамды минем...» ............
«Хыялларым тыялмадым...» ................

Йокысыз төн
Сәлам сезгә ........................
Ышанасы килми ......................
Болытлар ..........................
Эңгер ............................
Тынлык ...........................
Моңлы мизгел .......................
Матурлыкка баш ияргә ашык ..............
Җырга ...........................
Уйна әле, гармун .....................
Төнге гармун ........................
Туган ягыма .........................
Халкыма ..........................
Телең бетсә ........................
Тукайга ...........................
Яшә, Казан! ........................
Әтиләр ...........................
Балачакны сагыну .....................
Балачак ...........................
«Су өстендә ник бер дулкын...» ..............
Әни янында ........................
Әнкәйгә ..........................
Әнине сагынып ......................
Рәхмәт сиңа, җырым ....................
«Нәрсәдер эшлисе килә...» ................
Мин җыр булып калдым ..................
Бәхет теләрмен ......................
Өзелгән кыл ........................
Изге йөрәк .........................
Җыр .............................
Музыка ...........................
Йокысыз төн ........................
Давылларга кердем ....................
Китә кеше .........................
Вакыт ............................
Гомер юлында .......................
Кайту ............................
Кайттыңмы? ........................
Кеше гомере ........................
Гомер аты .........................
Яктылыкка үрлә! ......................
Рәхмәт сиңа, язмыш ....................
Микулай дәдәй ......................
Бөрмәнчек .........................
Унҗидедә идек .......................
Электричкада .......................
Бәхет турында .......................
Сайлауда .........................
Кичерергә кирәк ......................
Дустыма ..........................
Бер танышка ........................
Юха елан .........................
«Авызың тулы пычрак сүз...» ...............
«Мин беләм, безне беткә дә...» .............
Таш йөрәк .........................
Кеше булып калып кара .................
Без югалдык ........................
«Болыннарда моңым калды...» ..............
Хыялый ...........................

Фотосурәт .........................
«Елама, зинһар! Аңламый...» ...............
Коры куаныч ........................
Ак фәрештә ........................
Үзем турында .......................
«Арды канат...» ......................
«Ап-ак кәгазь, тәлгәш-тәлгәш булып...» .........

Безнең ил
Безнең ил ..........................
Корбаш авылы көенә ...................
Торналар үттеләр .....................
Шүрәле ..........................
Көмеш яңгыр ........................
Әй тау буе .........................
Кичер мине .........................
Эзләмә, юк инде .....................
Кыйгач кашым .......................
Син икәнсең ........................
Айлы төндә .........................
Моңайма ..........................

Литературно-художественное издание

***Ибушев*** *Георгий Мифодиевич*

**СПАСИБО ТЕБЕ, ПЕСНЯ**

Стихи

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Ибушев*** *Георгий Мифодий улы*

**РӘХМӘТ СИҢА, ҖЫР**

Шигырьләр

Төзүчесе һәм мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсаншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.02.2007.
Форматы 70×90 1/32. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,61.
Шартлы буяу-оттиск 7,90. Нәшер-хисап табагы 5,72.
Тиражы 2000 д. Заказ С-141.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http: // tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.